
# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

1/ 2023

**Буыннан-буынга күчкән сәнгати тел кануннарына, халык иҗатының символик образлылыгына ирешү, читек җөе серләренә бәйле уникаль технологияне үзләштерү дә зарур. Боларга татар декоратив сәнгате, аның орнаменты мирасын өйрәнмичә генә керешү мөмкин түгел.**














Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан



# 2023 ел –
## *Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы*

Бу – 2022 елның – Россия халыклары мәдәни мирасы елының, Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителүгә 1100 еллыгының, мәдәни һәм табигый мирасны саклау турында ЮНЕСКО конвенциясе кабул ителүгә 50 еллыгының логик дәвамы. Бу безнең тарихи рухи-әхлакый матрицабызны, традицион нигезебезне саклауның мөстәкыйль хокукларын яклауга ил белән күтәрелгән елыбыз.

Шунысы да игътибарга лаек: мәдәният ул биналар һәм таш диварлар гына түгел. Безнең тармакта иң мөһим фактор булып Кеше тора. Тармакның идеаль моделе, өлгесе – сәләтле кешеләр белән эш итү системасы.

**Татарстан Республикасы мәдәният министры Ирада ӘЮПОВАНЫҢ йомгаклау коллегиясендәге чыгышыннан.
31 гыйнвар, 2023 ел**



## ЭЧТӘЛЕК

### ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ




4 **«Минем тарих – минем Татарстан!»**

6 **«Һәр спектакль җәүһәр кебек»**

11 **«Идегәй» спектакле – сәхнәдә**


### ҺӨНӘРЛЕ ҮЛМӘС...




12 Е. Шемелова **«Утлы язу» сәнгате**


### СӘНГАТЬ




20 Г. Вәлиева-Сөләйманова **Наилә Кумысникова. Рәссамның күркәм миссиясе**



**Түгәрәк уен**

№1 (47) / 2023


*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*

*Г. Тукай*


16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге

Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Разил Вәлиев
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

Директор: Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир: Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Рәмзия Гайфетдинова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы:
Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590. Журнал өч айга бер чыга. Бәясе иркен.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛.
Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 07.03.2023
Чыгу көне: 25.03.2023
Заказ: 066666 Тираж: 1000 экз.

Редакция һәм нәшер итүче:

420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
Телефон: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

«Визард» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Җиңү проспекты, 78

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.


**Тышлыкта: «Сандугач» панносы, 2021 ел. Рәссам Н. Кумысникова.**


© «Түгәрәк уен», 2023

## ӘДӘБИ МИРАС



29 Л. Мөхәммәтҗанова
**Дастан җырлары!**

35 Л. Мөхәмәтҗанова
**Халкыбыз иҗатында – асыл тамырыбыз**

## СӘХНӘ



38 С. Сәмитова
**Мөслимчә «Зәңгәр шәл»**

## ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ ЙОЛАЛАРЫ



42 Г. Мәгъсүмова
Т. Вәлиева
**Су юлы күрсәтү**

46 Р. Сәйфетдинова
**«Бәлеш урлау» йоласы**

## БЕЗГӘ ЯЗАЛАР

48 **Иманлы Апас ягының догалы бер бәйрәме**

## БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ



50 Р. Мөхәммәтова
**«Милләт горурлыгы булган шәхесләрне без зурламасак, беркем зурламас»**

## БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...



54 **«Сәйлән» кешеләргә шатлык бүләк итә**

57 **Исәнме, яз, килдеңме!**
(Җыр)

## ӨЙ КҮРКЕ – АШ



58 **Зур бәлеш**

## ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ

62 **Шахворд**

# «Минем тарих – минем Татарстан!»

**2022 елның декабрендә Милли китапханәдә «Минем тарих – минем Татарстан!» II Бөтенроссия бәйгесенә йомгак ясалды. Ул иҗат эшләре буенча тарихи хәтерне саклауга, туган як тарихын өйрәнүгә, гаилә архивлары белән кызыксынуга этәргеч бирү максатында оештырылган иде. Конкурсны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы,Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге гамәлгә куйды.**

Бер ай эчендә бәйгегә 113 иҗади эш килде. Катнашучылар: мәктәп укучылары, студентлар, укытучылар, журналистлар, китапханәчеләр, мәдәният хезмәткәрләре. Катнашучыларның иң яшенә – 11 булса, иң өлкәненә 74 яшь иде. Аларның барысын да Татарстан тарихына, туган җиргә мәхәббәт берләштерә – килгән эшләрдән шул күренә. Гаилә традицияләрен, йолаларны тасвирлаган эшләр аша республикада яшәүче халыклар тарихы чагыла.

Бәйге өч номинациядә үткәрелде: «Искиткеч кешеләр», «Туган җир», «Алар батырлыгы үлемсез».

**«Искиткеч кешеләр»** номинациясенә 36 эш килгән иде. Алар арасында – якташлар белән әңгәмәләр, хезмәт кешеләре, тыл ветераннары хакында репортажлар, укытучылар, табиблар, мәдәният хезмәткәрләре турында видеосюжетлар һәм башкалар бар.

**Җиңүчеләр – I яшь төркеме:**

*1. Байбулатова Чулпан Рамил кызы;*

*2. Сәлахетдинов Самат Руслан улы;*

*3. Зарипов Илһам Илгиз улы.*

**II яшь төркеме:**

*1. Фәттахова Нурфия Вагыйз кызы;*

*2. Хаҗиева Алмазия Индус кызы;*

*3. Арсланова Назлыгөл Фәнис кызы.*

**«Туган җир»** номинациясе катнашучылар арасында иң популяры булды. 53 катнашучы туган як мәдәнияте, тарихы, традицияләр, йолалар турында язган.

**Җиңүчеләр – I яшь төркеме:**

*1. Кадыйрова Камилә Марсель кызы;*

*2. Вильданова Инзилә Илгиз кызы;*

*3. Буряк Герман Эдуардович.*



**II яшь төркеме:**

*1. Кәлимуллина Юлия Александровна;*

*2. Кривилева Фәридә Минирахман кызы;*

*3. Нәбиева Гөлнара Флүн кызы.*

**«Алар батырлыгы үлемсез»** номинациясенә килгән 24 иҗади эштә – сугыш ветераннары һәм тыл хезмәтчәннәре белән әңгәмәләр, алар турында эссе, очерклар, видеороликлар.

**Җиңүчеләр – I яшь төркеме:**

*1. Шиһабиева Илүзә Илфат кызы;*

*2. Хөсәенова Зилә Искәндәр кызы;*

*3. Якупов Тимерхан Морат улы, Жуков Владислав Антонович.*

**II яшь төркеме:**

*1. Зимнякова Ирина Владимировна, Пузырькова Елена Петровна;*

*2. Хәбибуллин Фаил Әхмәдулла улы;*

*3. Галимов Айдар Фәргать улы.*









# «Һәр спектакль җәүһәр кебек»

**Татарстанда «Идел-йорт» халык театрлары фестивале республиканың мәдәни вакыйгалары арасында үз урынын алып торган чарага әйләнеп бара. Быел фестивальдә йөз театр коллективында 2000нән артык һәвәскәр артист катнашты. Халык театрлары спектакльләрен карарга Ленин исемендәге мәдәният сараена 4800дән артык тамашачы килгән иде. Унике театр коллективы финалга чыгып, аның алтысы лауреат исемен алды.**

Традиция буенча Гран-при алган театр коллективы үз спектаклен данлыклы Камал театры сәхнәсендә уйный. Һәвәскәр театр артисты өчен моннан да зур мәртәбә бармы?! Быел бу бәхеткә Мөслим районының Мөслим халык театры лаек булды. Алар тамашачыга Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ен күрсәтте.

Жюри да, тамашачы да, спектакльләрне караган профессиональ артистлар да халык театрларының профессионализмы үсүен билгеләп үтте. Мәсәлән, быел Балык Бистәсе районының Балтач (Юлсубино) авылы мәктәбендә халык язучысы Равил Фәйзуллинның музей салоны ачылу тантанасына кунак булып кайткан Равил Шәрәфиев тантананың икенче бер шәрәфле кунагы, Татарстан Республикасының Дәүләт Советы



**Мөслим халык театры**


Актаныш районының «Нур» халык театры

Рәисе урынбасары Марат Әхмәтовка халык театрларын мактап болай диде: «Ике ел элек безнең районда үзешчән театрлар фестивалендә катнаштым. Анда шулкадәр әйбәт спектакль күрсәттеләр. Туфан Миңнуллинның «Әниләр һәм бәбиләр»ен шундый шәп уйнадылар, безнең театрдан ким түгел. «Казанда уйнагыз, республикада күрсәтегез», – дидем. Җитәкчесе: «Минем анда сыер савучылар», – диде. Шуны Казанда күрсәтеп, халыкны шаккаттыра алмадык».

Сүз уңаеннан, быел Балык Бистәсе халык театры легендар татар актрисасы Исламия Мәхмүтованың «Мәхәббәт чишмәсе» пьесасын сәхнәләштереп, II дәрәҗә лауреат исемен алды.

Фестивальнең жюри рәисе, Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрының сәнгать җитәкчесе Олег Кинҗәгулов та спектакльләрне җәүһәргә тиңләде. «Финалга чыккан 12 спектакльнең күбесе – Кама аръягы төбәкләреннән. Шунысы шатландыра – безнең як (Чаллыда эшләгәч, шулай дип әйтергә тулы хокукым бар) иҗади яктан көчлерәкме, фантазия ягыннан баеракмы... Казан коллективларының эше белән чагыштыргында, Мамадышта, Актаныштта, Балык Бистәсендә спектакль бар, аның концепциясе бар. Чистай театр коллективы Островскийны күрсәтеп, профессиональ коллективлар да бик алынмаган материалга алынганнар, 3 сәгать бик җиңел узды. Бәлки, профессиональ театрларның ярдәме тәэсир иткәндер – һәвәскәр театрларның үсеше күренә. Хәзер минем өчен республика



Балык Бистәсе халык театры



**Арча халык театры**

халкының нәрсә белән яшәве ачыклана башлады, күзаллавым киңәя. 12 спектакльнең һәрберсе җәүһәр кебек. Кайсына Гран-при бирәсен дә күзаллап булмый. Алар һәркайсы үзенчә», – диде.

Әйе, халык театрларының елдан-ел осталыгы арта – монда фестивальне оештыручыларның һәм профессиональ театрларның да өлеше гаять зур. Ел дәвамында дәүләт театрларында халык театрлары өчен иҗади лабораторияләр оештырылып килә. Татарстанның 11 профессиональ театры халык театрлары режиссерлары, актерлары, концертмейстерлары һәм башкалар өчен осталык дәресләре уздырды. Һәвәскәр театр вәкилләре спектакльне музыкаль яктан бизәү, яктырту буенча дәресләр алды. Катнашучылар өчен сәхнә хәрәкәте, пластика, сөйләм теле буенча тренинглар узды.

Нәтиҗә күз алдында – коллективлар «Зәңгәр шәл» кебек катлаулы әсәрләргә алына һәм аны гран-при алырлык дәрәҗәдә уйнап чыга. Афәрин!

P.S.: Алдарак телгә алынган музей ачылу тантанасында Татарстан Республикасының Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов: «Районнардагы үзешчән театрлар телне саклау өчен бик булыша. Анда – чын әдәби, матур татар теле», – диде.

Әйе, халык театрлары – чын әдәби матур татар телен саклаучы хәзинә. Бу яктан караганда да бу фестиваль яшәргә һәм үсәргә хаклы. Яшәсен «Идел-йорт»!

Конкурсны гамәлгә куючы – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге, Бөтендөнья татар конгрессы һәм Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры.

**Фестиваль спектакльләрен бәяләүче белгечләр:**

**Олег Кинҗәгулов** – *конкурсның жюри рәисе, Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрының сәнгать җитәкчесе;*

**Наталья Табачкова** – *Гнесиннар исемендәге Россия музыка академиясе доценты;*

**Луара Шакирҗанова** – *Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының музей мөдире, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе;*

**Луиза Шарова** – *шагыйрә, Г. Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театры директоры;*

**Миләүшә Хәйруллина** – *композитор, концертмейстер;*

**Илназ Хәйбуллин** – *Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының куелыш бүлеге мөдире.*



Баулы халык театры



Чаллы халык театры

**«Идел-йорт» театр фестивалендә Гран-при алган театр коллективлары:**

*2008 ел – Кукмара районы мәдәният йортының театр коллективы;*

*2009 ел – Чирмешән районы мәдәният йортының театр коллективы;*

*2010 ел – Әтнә районы мәдәният йортының театр коллективы;*

*2011 ел – Актаныш районы мәдәният йортының театр коллективы;*

*2012 ел – Азнакай район-шәһәр мәдәният сараеның театр коллективы;*

*2013 ел – Арча районы мәдәният йортының театр коллективы;*

*2014 ел – Кукмара районы мәдәният йортының театр коллективы;*

*2015 – Теләче районы мәдәният йортының театр коллективы;*

*2016 ел – Мөслим районы мәдәният йортының халык театры коллективы;*

*2017 ел – Актаныш районы Киров авылы мәдәният йортының халык театры коллективы;*

*2018 ел – Бөгелмә шәһәре Татар мәдәният үзәгенең халык театры коллективы;*

*2019 ел – Сарман районы мәдәният йортының халык театры коллективы;*

*2020 ел – Актаныш районы Киров авылы мәдәният йортының халык театры коллективы;*

*2021 ел – Питрәч районы «Балкыш» халык театры коллективы.*



**Актаныш районының «Ихлас» халык театры**



**Чистай халык театры**



**Мамадыш халык театры**

Яңалыклардагы фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан



# «Идегәй» спектакле – сәхнәдә

**Республикада 2023 ел – Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы дип игълан ителде. Бөтендөнья татар конгрессы Милли шурасы 2023 елны «Дастаннар елы» дип билгеләде һәм бу елны Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры «Идегәй» спектакле белән башлап җибәрде. Спектакль Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына багышлап куелды.**

Татар халкының 500 еллык тарихы булган дастанны театрның баш режиссеры Туфан Иманметдинов сәхнәләштерде.

– «Идегәй» дастаны тамашачыларда әдәби телебезгә, рухи мирасыбызга, милли мәдәниятебезгә ихтирамны арттырыр дигән өметем зур. Бу Тинчурин театрында яңалык та, борылыш та булачак», – диде ул.

Дастанда Идегәй ролен яшь актер һәм режиссер Илнур Гарифуллин башкара. Спектакльнең рәссамы – Алия Гайнуллина, хореограф – Марсель Нуриев, хормейстер – Алия Хәмзина, музыкаль җитәкче, дирижер – Ильяс Камал. «Идегәй» спектакленә көйләрне яшь композитор, Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясен тәмамлаган Фәрһад Бәхтияри иҗат итте.

Спектакльгә әзерлек вакытында «Ачык университет» укыту платформасы Тинчурин театры белән берлектә татар дастаннарына багышланган «Татар дастаны ни сөйли?» дип аталган яңа курс оештырды. Шул уңайдан Тинчурин театрында язучы, «Идегәй» дастанының бер вариантының мөхәррире Галимҗан Гыйльманов, тарихчы Дамир Исхаков лекцияләр уздырды. Шулай ук, «Ачык университет» белем бирү проекты кысаларында, төрки сугыш сәнгате буенча мастер-класс үткәрелде.

Рәмис Нәҗмиев фоторәсеме. Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрының матбугат үзәге архивыннан

# «УТЛЫ ЯЗУ» сәнгате

*Евгения ШЕМЕЛОВА,*
*Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге методисты*

**Сәнгати эмаль сәнгатенең дүрт мең еллык тарихы бар. Россиягә әлеге борынгы декоратив-нәфис кәсеп X гасырда Византиядән килгән. Ул чакларда бу сәнгати эмаль «финифть» дип йөртелгән. XIX гасырда гына «финифть» сүзен «эмаль» термины алыштырган.**



«Юл» элмә бизәге



«Ай» алкалары

Эмаль – металл оксидларыннан төрле төсләргә кергән, катып калган пыяласыман масса. Эмаль сәнгати фикерне күрсәтү, металлны бизәү чарасына әверелсен өчен металл белән эмальне тоташтыра ала торган махсус технологияләр кулланыла. Моның өчен порошок хәленә китерелгән эмальне металл өстенә сылап 700 дән 900 градус Цельсийга кадәр кат-кат яндырып чыныктыралар. Византиядә бу төр кәсеп юкка гына «утлы хат» дип аталмаган. Гасырлардан гасырларга эмаль белән эш итү сәнгатьнең элитар төре булып саналган, чын шедеврлар тудыру өчен искиткеч сәнгати осталык һәм яндыру серләрен төгәл белү соралган.

Ювелир эмаль сәнгате һәм һөнәре бүгенге Татарстан территориясендә дә булган. Археологик табышлар шуны раслый – урта гасырларда



**«Афрасиаб» муенсасы**



Ольга Родионова

Болгар чорында да, Алтын Урда чорында да безнең осталар эмальне белгән һәм аны табу техникасыннан хәбәрдар булган. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында Балык Бистәсендә зәркәнчелек эше оештырылган.

Татарстан җирлегендәге элеккеге осталар эшен Гөлназ Афанасьева (Хаҗиева) һәм Ольга Родионова кебек бүгенге рәссам-эмальерлар үстерә.

«Ольга Михайловна белән иҗади тандем Казан халык һөнәрчелеге техникумында укыганда барлыкка килде. Без анда зәркәнчелек һөнәренә өйрәндек, – ди Гөлназ Мирзаҗановна. – Ювелир эшләнмәләр ясаганда безгә төсләр, якты буяулар җитми башлады һәм без остазыбыз Евгений Бакакин белән бергә кайнар эмаль техникасында эшләп карадык. Тора-бара эмаль белән мавыгуыбыз даими эшебезгә әверелде. Реставрация, архитектура һәм сәнгати эшләнмәләр белән фәнни-тикшеренү институтындагы биш еллык эшчәнлегебез дә зур тәҗрибә бирде».



**«СӨБҺАНАЛЛАҺ»**

Алга таба рәссамнар шамаилларны үзләренең авторлык каллиграфиясе нигезендә ясый башлаган.



**ЗӘРКӘНЛЕ ШАМАИЛ** «عشق الله معبود الله» – «Аллаһы – мәхәббәт, сөеклебез һәм яратучыбыз». Бу афоризм әйләнә буйлап укыла, аның *башы да, азагы да юк, ул чиксез. Формасы – сигез почмаклы, исламда кулланыла торган символ. Зәңгәр төс – чиксез һәм мәңгелек күк – Тәңре. Үсемлекле орнамент татар стилендә эшләнгән. Композиция үзәгендәге табигый таш очсыз-кырыйсыз галәм дигән тәэсир калдыра.*

> Без һаман да эзләнүдә. Шуңа да остаханәбез «Райдо» дип атала. Райдо – «юл», «сәяхәт» мәгънәсен бирә торган рун билгесе-символы. Бу безнең дөньялар тарихына, диннәр фәлсәфәсенә сәяхәтебез. Без шулардан үз эшебезгә илһам алабыз.



**ЗӘРКӘНЛЕ «СУФИ» ШАМАИЛЕ**

«مت قبل موتك و حاسب نفسك قبل حسابك». *Шәрыкъ дөньясының күренекле фикер иясе, суфилык фәлсәфәсе һәм шигъриятенә нигез салучы Җәләлетдин Румига багышланган шамаил шәрыкъ әкиятләрен хәтерләтә. Менә-менә серле бүлмәнең затлы ишеге ачылып китәр дә, могҗизалар һәм ачышлар дөньясына килеп эләгербез кебек. Эмальнең яшел төсе һәм хризопраз ташы, аларның ялтыравы күңелдә ышаныч, өмет һәм мәхәббәткә урын барлыгын искәртә төсле.*



Гөлназ Афанасьева (Хаҗиева)

Хәзер рәссам-эмальерлар «Райдо» дип аталган үз остаханәләрендә кайнар эмаль, кыйммәтле һәм ярымкыйммәтле ташлар белән гаҗәеп матур авторлык зәркән бизәнү әйберләре иҗат итә. «Без һаман да эзләнүдә. Шуңа да остаханәбез «Райдо» дип атала. Райдо – «юл», «сәяхәт» мәгънәсен бирә торган рун билгесе-символы, – дип ачыклык кертә Гөлназ Афанасьева. – Бу безнең дөньялар тарихына, диннәр фәлсәфәсенә сәяхәтебез. Без шулардан үз эшебезгә илһам алабыз».

Рәссамнарның ювелир шамаиллары сокландыра, заманча сәнгатьтә аларга тиңдәш юк. Гарәп каллиграфиясен алар төрле осталардан өйрәнгән. Мәсәлән, Согуд Гарәбстаны профессоры Җамал Кибаси Әл-Ребеа куфи язуына өйрәткән. «Сөбһаналлаһ» шамаилы аның белән автордаш буларак иҗат ителгән.

«Лә иләһә илла-Ллаһ» шамаилы танылган каллиграф Әхмәт Камал (Сирия) эше мотивлары буенча башкарылган.

Безнең регионның мәдәни һәм рухи мирасы өлкәсендә эзләнүләр рәссамнарны Бөек Ефәк юлына чыгарган. Бу аларга иран, рус, болгар, татар, һинд, кытай, үзбәк һәм башка халыкларның мотивларын кулланырга мөмкинлек биргән. Шулай итеп, Казан ханлыгы чорының идарә атрибутлары коллекциясе (таҗ, юл таягы, хәситә), «Зилант» геральдик брошкасы, «Умай» алкалары, «Кәгъбә» йөзеге, «Шәрыкъ җаны», «Ефәк юлы» муенсалары, «Идел буе Болгары» гарнитуры, «Афросиаб» коллекциясе һәм башка бик күпләр барлыкка килгән.

**«Үткән гасырлардагы кебек үк, эмаль сәнгате хәзер дә зур хезмәт сорый торган катлаулы процесс. Аны механикалаштырып та булмый, конвейер системасы да бармый, бу – кул хезмәте.**



**«КӘГЪБӘ» ЙӨЗЕГЕ.** *Йөзеккә Исламдагы изге урын идеясе салынган. Йөзеккә зөбәрҗәт каш куелган. «Аллаһ» – الله – каллиграфик язуы кайнар эмаль техникасында эшләнгән.*



**«ЗИЛАНТ»** *геральдик брошкасы барокко стилендә эшләнгән. Казан символы булган Зилант еланы турында борынгы риваятьләр буенча милли элементлар кулланып ясалган.*



**«УМАЙ»** *авторлык колак алкалары*



**«ЗИЛАНТ ӘКИЯТЛӘРЕ»** *муенсасы*

Рәссамнарның эше Татарстанда, Мәскәүдә, Дубайда, Бохарада, Ташкентта, Калининградта узган күргәзмәләрдә катнашкан. Һәр эшләнмә тамашачыны таң калдырган, әмма башта барысы да ханнар стилендә ясалган таҗ-бүреккә игътибар итә икән. Аны ясау өчен рәссамнар төрки халыкларның баш киемнәре тарихын өйрәнгән, нигез итеп, Сөембикәгә багышланган картиналардан ханбикәнең баш киеме, Иван Грозный өчен тегелгән Казан бүрке алынган. Шулай ук Нугай урдасындагы затлы төркиләр турындагы тарихи белешмәләр, гравюралар өйрәнелгән. Таҗ бронза, фианитлар, фирүзә, энҗе, Италия бәрхете, йон кулланып, бер ел дәвамында ясалган. Бүрекнең биеклеге 37,5 сантиметр.

«Үткән гасырлардагы кебек үк, эмаль сәнгате хәзер дә зур хезмәт сорый торган катлаулы процесс. Аны механикалаштырып та булмый, конвейер системасы да бармый, бу – кул хезмәте, – ди Гөлназ Афанасьева. – Кайнар эмальдән тыш, металлны сәнгати эшкәртүнең төрле техникаларын кулланыбыз. Идеядән һәм эскиз ясаудан



**«АЙ» МУЕНСАСЫ** – *хатын-кызны саклаучы талисман. Ул аларга иң яхшы сыйфатларны күрсәтергә, гармония һәм мәхәббәтне үз тормышларына җәлеп итәргә булыша.*



**«КӨНЧЫГЫШ ҖАНЫ»** *муенсасын иҗат итәргә борынгы ислам архитектурасы һәм декоратив сәнгать рухландырган.*



**«БОЛГАР» ГАРНИТУРАСЫ.** *Моны ясарга Идел буе Болгар дәүләте тарихы һәм мәдәнияте рухландырган.*



**«ТАВИС»** *брошка-кулоны модерн стилендә эшләнгән. Тавис – кояш һәм чәчәк ату, рухи һәм матди иминлек символы.*



**Хан таҗы**




**«Ерткыч» йөзеге**

башлап, әзерләп бетергәнчегә кадәр, иҗат эшен тулысы белән икәү башкарабыз».

Традицион милли сәнгатьне үстерүгә керткән өлешләрен күздә тотып, «Райдо» остаханәсенә кайнар эмальле зәркән сәнгатенә кагылышлы проектларны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте гранты бирелгән.

Фоторәсемнәр Гөлназ Афанасьеваның (Хаҗиева) шәхси архивыннан

# *Бергәләп бизибез!*



# Наилә КУМЫСНИКОВА. Рәссамның күркәм миссиясе

*Гүзәл ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА,*
*сәнгать фәннәре докторы*



**Кумысникова Наилә Халит кызы – театр һәм декоратив-гамәли сәнгать рәссамы, Татарстанның халык рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2009). 1958 елның 4 апрелендә Казанда туган. Казан сынлы сәнгать училищесын (1977), Суриков исемендәге Мәскәү сынлы сәнгать институтының театраль-декорация бүлеген (1983) тәмамлаган. Казан сынлы сәнгать училищесында укыткан (1983-1996). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1987). Бакый Урманче исемендәге Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы премиясе лауреаты (1999).**

Наилә Кумысникова – сәнгати югарылыкка күтәрелү өчен үз юлын тапкан, гайре табигый иҗади биографияле рәссам. Ул үз дигәнендә нык торып һәм онытылып, киләчәк белән үткәннәр арасында күпер сала – борынгылар мирасын яңа сыйфатта торгыза. Рәссамны якыннан белгән кешеләрне аның сәнгатьтә үз миссиясен яхшы аңлап эш итүе, ихтыяр көче, матурлык идеалына омтылышы сокландыра. Аның үз иҗади билгеләнешенә ышанычының тамырлары тирән – Кумысниковларның нәсел шәҗәрәсенә тоташкан.

Наиләнең әти-әнисе татар интеллигенциясенең матур вәкилләре. Әтисе – Халит Кумысников, танылган театр тәнкыйтьчесе, сәнгать белгече, татар театрын өйрәнгән күренекле галим. Әнисе – Асия Хәйруллина – Татарстанның атказанган артисты, гомеренең иң матур елларында Камал театры сәхнәсендә балкыган актриса.



**«Сәнгать агачы» панносы, 2006 ел.**
**Күн, замша, мамык җеп**

Наилә театр тирәлегендә, театр диварлары арасында үскән бала диярлек. Бәбинең беренче айлары костюмерлар цехында узган – баланың бишеге дә мех белән каймаланган бүрек булган, ди. «Бүректә үскән» дип шаяртырга яраткан театр хезмәткәрләре. Ул беренче адымнарын да театрда атлап киткән, коллектив белән гастрольләргә йөргән. Спектакльләрдә бала ролен башкарырга да аны чыгарганнар. Гаиләдәге иҗади атмосфера һөнәр сайларга да юнәлеш биргән, әлбәттә. Алгарак китеп әйтим: Наилә ханымның ире – Александр Федотов, күренекле рәссам, уллары Җәмил дә гаилә традицияләрен дәвам итә – архитектор һәм дизайнер.

Наилә Кумысникова балачактан ук рәссам булачагын белгәнен искә ала. Яраткан шөгыле дә бөек рәссамнарның, аеруча, Рембрандтның әсәрләре төшерелгән открыткаларны карау була. Әтисенең шәхси китапханәсендә сакланган сәнгать буенча китаплар да булачак рәссамны формалаштыруга үз өлешен кертә. Балалар рәсем сәнгате мәктәбен тәмамлагач, ул укуын Казан сынлы сәнгать училищесында дәвам итә. Әлбәттә, театр-декорацияләр бүлеген сайлый.



**Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең «Көмеш беләзек» биюе өчен костюмнар. 2008 ел**

Биредә сценографияне Казанда билгеле рәссам Кәнәфия Нәфыйков алып бара. Училищеда ул әтисе куйган өйрәнчек спектакльләрне бизи: декорацияләр һәм костюмнар өчен эскизлар ясый. Шундый спектакльләрнең берсен – Гарсиа Лорканың «Бернарда Альба йортын» Суриков исемендәге сынлы сәнгать институтына кергәндә «ирекле тема» буларак сайлый. Әлеге эшне сценография корифее М.М. Курилко-Рюмин охшатып, Наиләне үз остаханәсенә ала.

Сынлы сәнгать институтында уку еллары, күренекле остазларда белем алу Наилә ханымның профессиональ үсеше өчен зур мәктәп була. Студент чагында ук Казанда республика күргәзмәсендә, Мәскәүдә бөтенсоюз күргәзмәсендә катнаша. Яшь сценограф яңа материаллар, новаторлык формалары белән кызыксына: аның диплом эше – С. Прокофьевның «Любовь к трем апельсинам» спектакленә декорацияләр һәм костюмнар эскизлары шуңа дәлил. Эскизлар образларның якты чишелеше һәм җыйнак формалары белән аерылып тора.

Үз иҗади концепциясе һәм сәхнә карашы булган талантлы рәссам Мәскәүдә укуын тәмамлап, Казанга кайта. Аның декорацияләре җанлы, хәрәкәтчән була. Кумысникова спектакльнең динамик образы турында остазы дәресләрен яхшы үзләштергән – ул бизәлешнең бертөрлелегеннән һәм декорацияне гади антуражга әверелдереп калдырган хәрәкәтсезлектән качарга тырыша. Камал театрында Рабит Батулланың «Елан тавы» (1984), Әлмәт театрында Кәрим Тинчуринның «Җилкәнсезләр» (1984), Казанның «Экипаж» эксперименталь театрында А.С. Пушкинның «Маленькие трагедии» (1986), Татар яшьләр театрында Диас Вәлиевнең «Намус хөкеме» (1991), «Адым» татар яшьләр театрында Кәрим Тинчуринның «Ил» (1992), Бөгелмә рус драма театрында куелган М. Горькийның «Последние» пьесасына (2001) һәм башка спектакльләргә декорацияләрне һәм костюмнарның эскизларын ясый. Әмма җирле театрлар сценографиясенә яңа агым өстәү нияте каршылыкка очрый һәм Кумысникова Казан сынлы сәнгать училищесында укыта башлый. Аның укучылары арасында танылган театр рәссамнары да, дизайнерлар да, гамәли сәнгать рәссамнары да бар. Болар М. һәм О. Покалевлар, Е. Ермолина, Д. һәм Л. Җәләлетдиновлар, Д. Нәүрүзова, А. Исмәгыйлева, Л. һәм С. Рябининнар һәм башкалар.



**«Мәңгелек хәрәкәт» панносы, 2011 ел.**
**Күн, ефәк җеп**

Театр-декорация сәнгатенә хас киң диапазонлы иҗади потенциалы Кумысниковага яңа һөнәри юнәлеш алырга ярдәм итә. Ул татар декоратив-гамәли сәнгате, аның данлыклы төре – күн мозаика белән кызыксынып китә. Моны һич кенә дә җиңел юл сайланган дип әйтеп булмый, киресенчә, сценографиядән аермалы буларак, башка авырлыклар көтә. Биредә иҗади гына түгел, эшләнмәләрнең тиражын булдыру һәм җитештерүне җайга салу кебек оештыру мәсьәләләре дә алга килеп баса.

Наилә Кумысникова күн мозаика технологиясен һәм орнаменталь телен үзләштерүдә беренче адымнарын ясаган туксанынчы елларда әле рәссам Софья Кузьминых актив эшли, Арчада милли аяк киемнәре дә җитештерелә һәм ул производствоны рәссам Илдус Гайнетдинов җитәкли иде. Алар заманча күн мозаика сәнгате үсешенә үз өлешен кертсә дә, Россия, Европа һәм хәтта дөнья модасы базарын канәгатьләндерерлек югары сыйфатлы эшләнмәләргә ихтыяҗ зур иде. Моның өчен күн эшләнмәләре формасы һәм моде-

ле эстетикасына яңача караган рәссам – стилист һәм модельер кирәк була. Инновацияләргә әзерлек һәм сәнгати сизгерлек профессиональ мәктәп аша килә, Кумысникова белем алган Суриков институты остаханәсе шундыйлардан. Бу иҗатта новаторлык эзләнүләре өчен кирәкле төп алшартларның берсе генә, әлбәттә.

Буыннан-буынга күчкән сәнгати тел кануннарына, халык иҗатының символик образлылыгына ирешү, читек җөе серләренә бәйле уникаль технологияне үзләштерү дә зарур. Боларга татар декоратив сәнгате, аның орнаменты мирасын өйрәнмичә генә керешү мөмкин түгел. Әле бит күн мозаика, аерым алганда, милли аяк киеме җитештерү өчен чигү һәм



**«Идегәй» ир-егетләр комплекты, 2008 ел.**
**Күн, мамык җеп**



**«Алмагач» панносы, 2011 ел.**
**Күн, ефәк җеп**

аяк киеме тегү техникасына ия булган белгечләр дә кирәк.

Ниһаять, рәссам-дизайнер белән чигүче һәм аяк киеме модельеры тандемы оеша. Әлеге берләшүдән аяк киеме конструкциясе һәм бизәкле күн кисәкләрен тегү белән беррәттән бизәп тә барган «Казан (татар) җөенә» яңача караш барлыкка килә. Ефәк җепләр куллану һәм җөйне эреләндерү идеясе туа, бу бизәк линияләренә, рәсемгә акцентны арттыра. Наилә Кумысникованың беренче әсәре юкка гына «Ел фасыллары» дивар панносы (1995) түгел бит инде, биредә төп сәнгати эффектны орнаментның композициясе бирә. Панного орнаменталь иҗат законнары буенча стилизацияләнгән сюжет сурәтләре кертелә.

Гамәли сәнгать рәссамы буларак Наилә Кумысникованың һөнәри казанышлары аның новаторлык фикерләвендә һәм халык традицияләрен аңлатып биргәндә үзен ирекле тотуда чагыла. Аның авторлык уй-ниятләрен тормышка ашыру өчен Казан Кремлендә Татарстан Президенты карамагындагы Мәдәниятне үстерү фонды химаясендә «Булгари» (нәзек итеп эшкәртелгән күн күп халыкларда шулай атала) иҗат остаханәсе оештырылу – рәссамның профессиональ карьерасы өчен зур иҗади күтәрелеш була. Сүнеп барган сәнгать төрен җанландырып җибәрү өчен биредә күн мозаикадан эшләнмәләр, үрнәкләр әзерләнә башлый.

Производство юкны бар итүдән башлана. Рәссамның үз алдына куйган төп максаты – алга таба тиражлау өчен коллекция иҗат итү. Уникаль һәм серияле эшләнмәләр өчен үрнәкләр – ир-ат һәм хатын-кыз читекләре, кием өлешләре (камзуллар, курткалар, жилетлар), хатын-кыз сумкалары, идән һәм диван мендәрләре һәм башкалар ясала. Остаханәдә эшләнгән үзләре стильле, үзләре милли әйберләргә ихтыяҗ зур була, алар киемнәрдә этник юнәлешкә бәйле модалы тенденцияләргә дә туры килә.

Остаханә эшчәнлеге җәмгыятьтә күн мозаиканы көнкүрештә һәм кием ансамблендә куллануга игътибарны арттыра, татар сәнгатенең бу төрен рәссамнарның иҗат практикасына кертүгә этәргеч бирә. Ни кызганыч, Наилә Кумысникова остаханәдә озак эшләми – нибары 2 ел. Сәбәбе – остаханә эшчәнлегендә табыш алу хәлиткеч рольне уйный башлый, бу инде сәнгати сыйфатны беренче урынга куйган рәссамның иҗади максатлары белән каршылыкка керә. Нәрсә генә булса да, остаханә эшчәнлеге тәҗрибәсе мондый производствоның уңдырышлылыгын, сүнеп барган халык һөнәрчелеген торгызу потенциалын күрсәтә.

**«Алтынчәч» комплекты, 2008 ел.**
**Күн, ефәк җеп**





**«Болгар йолдызы» панносы, 2017 ел.**
**Күн, ефәк җеп**

Наилә Кумысникова башлаган иҗат юлын яңа шартларда дәвам итә – 1997 елдан ул мөстәкыйль эшли башлый, заказларны башкару өчен чигүче осталарны җәлеп итә.

Бүгенге көндә Наилә Кумысникова күн мозаикасы өлкәсендә әйдәп баручы рәссамнарның берсе. Аның әсәрләре белгечләрнең югары бәясен ала, илдә һәм халыкара күргәзмәләрдә уңыш казана, оригинальлеге һәм нәзәкатьлелеге, башкару осталыгы белән аерылып тора.

Наилә Кумысникованың профессиональ горурлыгы – эре җөй формасы, аны күп рәссамнар яратып куллана. Ул җөйсез бизәкле итекләр, ирләр читекләре әзерләүнең борынгы технологияләрен торгыза. Күп төсләрдән торган җөйне дә актив куллана – ул декорның мөстәкыйль элементы булып тора.

Төсләр композициясендә Наилә Кумысникова күн мозаика чәчәк аткан чор – XVIII гасыр азагы – XIX гасыр урталары традицияләренә мөрәҗәгать итә: төсләрне яраштырганда табигый буяулар төсмерләренә якынайтырга тырыша. Аңа төсләр контрасты белән үзенә җәлеп иткән композицияләр дә ят түгел.



**«Болгар төшләре» панносы, 2018 ел.**
**Күн, ефәк җеп**

Нәфис силуэтлы модалы хатын-кыз итекләрендә, аларның сумкалы комплектларында («Зөбәрҗәт», «Алсу» (икесе дә – 1996); «Ал» (1997); «Фирүзә» (2002); «Сапфир» (2003)), жилетларда, билбауларда һәм киемнәрнең башка аксессуарларында күн мозаика традицияләрен кулланып, заманча милли стилистикалы әйберләр иҗат итә. 2005 елда – Казанның 1000 еллыгы уңаеннан аның тарафыннан күн галантереясе фабрикасында күпләп чыгару өчен хатын-кыз сумкасының 330 төрле сувенир моделеннән торган, зурлыгы ягыннан моңарчы күрелмәгән коллекция эшләнә.

Рәссам күн эшләнмәләр модельләре белән генә чикләнми, аларны башка материаллар белән дә берләштерә, стилистикага яңа алымнар кертә, сәнгати һәм техник чаралар диапазонын киңәйтә. Әйтик, «Ал» комплектына кергән кызыл читекләр һәм сумкада монументаль пластикада һәм нәфис металлда кулланылучы зиннәтле Алтын Урда сәнгате мотивлары файдаланылган. Бу комплект күн һәм замшаны (йомшак күн) берләштереп эшләнгән.

Үзенең һәр әсәренә Наилә Кумысникова иҗади идеяләр кертә, борынгы алымнар белән экспериментлар ясый. Мәсәлән, чагыштырмача



**«Алтын Болгар» сервизы Мәрҗани фонды заказы белән Санкт-Петербургның Император фарфор заводында эшләнгән. 2012 ел. Рәссам Н. Кумысникова.**
Сөяк фарфоры, «гөмбәз» формасы авторы Ю. Троицкий



**«Алтын гөмбәзләр» сервизы. Мәскәү Җәмигъ мәчете ачылу уңаеннан Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте заказы. 2015 ел. Рәссам Н. Кумысникова.**
Сөяк фарфоры, «гөмбәз» формасы авторы Ю. Троицкий

күптән түгел иҗат иткән соңгы эшләренең берсендә – диван мендәрчекләре сериясендә (2010 еллар) татарның тамбурлы чигешенә мөрәҗәгать итә, аларны мозаика алымнары белән стилизацияли, чигешләргә характерлы булган бер төсле фон куллана. Күп кенә эшләнмәләрендә мозаика белән бергә алтынлап һәм көмеш чигүләр куллана яки «Казан җөе»нә охшатып тегелә. Рәссамга абстракт композицияләр, төсләрнең контрастлыгы кебек авангард чишелешләр дә ят түгел.

Наилә Кумысникова иҗатында интерьерда кулланыла торган дивар паннолары мөстәкыйль юнәлеш алган. Алар ассоциатив-символик яки сюжетлы-тематик циклларга берләшә, тасвирый характердагы мотивлар, символлар белән тулыландырыла. Шундый панноларның иң эреләреннән берсе Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының вестибюлен бизи. Аның бай орнаментлы декоры ишектән кергәч тә күзгә ташлана. Симметрик композицияле стилизацияләнгән мотивларда традицион символика: канатларын киң җәеп кояшка каршы очучы кош, тормыш агачы янәшәсенә кунаклаган парлы бәхет кошлары, лалә чәчәге мотивы һәм башкалар халык фәлсәфәсендә дөнья яралышын чагылдыра. Башка паннолар композициясе татар фольклоры – мифлар, риваятьләр сюжетларына корылган, Болгар чорыннан башлап, татар халкының орнаменталь мирасын киңәйтә.

Мәсәлән, «Ак кошлар» панносы композициясендә символикасы мифологиягә нигезләнгән металл болгар көзгесе сурәтләнгән. Паннонының формасы (үлчәме дә) да, килешеп торган кысалары да аны иҗтимагый һәм шәхси интерьерларда якты акцент итә.

Наилә Кумысникованың әсәрләре сәнгать яратучыларның казанышына әверелде. Алар арасында президентлар, күп кенә дәүләтләрнең югары затлары, коллекционерлар, танылган артистлар, мәдәният әһелләре һәм башкалар бар. Рәссамның иҗади потенциалы Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, «Салават» театр студиясе концертларының сәхнә бизәлешендә һәм костюмнарында, XVIII-XIX гасыр татарларының бизәкле аяк киемнәрендә, болгар костюмын һәм Казан Кремлендәге археологик эзләнүләр вакытында табылган татар хәрбиенең сугыш коралларын тарихи реконструкцияләгәндә чагылыш таба. Аның эшләре Татарстан Милли музеенда, Татарстан Дәүләт Сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли-мәдәни үзәгендә, «Казан Кремле» дәүләт музей-тыюлыгында, Мәскәүнең «Мәрҗани фондында» һәм башка тупланмаларда саклана.

Наилә Кумысникованың иҗади мирасы масштаблары белән шаккатыра, сан ягыннан карасаң, шулкадәр күп әсәрләр иҗат ителгән – санап бетергесез. Шулай да рәссам эшчәнлегенең зур өлеше сыйфат казанышы яссылыгында ята. Наилә Кумысникова күн мозаика сәнгатен яңа дәрәҗәгә күтәрә алды, ул заманчалаштырып форманы гына камилләштереп калмады, күп гасырлык традицияләрне үстергән татар милли стилен барлыкка китерде. Рәссамның күркәм миссиясе нәкъ менә шунда да инде.

# ДАСТАН җырлары

*Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,*
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре*



**Көйләп тә әйтелгән, язмача да таралган «Түләк», «Бүз егет», «Кыйссаи авык», «Кыйссаи Сәкам», «Гыйсә улы Амәт», «Шаһсәнәм һәм Гариб», «Хурлуга белән Һәмра», «Каһарман Катил», «Кисекбаш кыйссасы», «Чура батыр хикәяте», «Күр углы Солтан»,«Таһир белән Зөһрә», «Йосыф китабы», «Сәйфелмөлек», «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Идегәй», «Гыйсә улы Амәт», «Аксак Тимер», «Бүрихан» һәм башкалар – болар татар китап культурасын үстерүгә зур йогынты ясаган, язма әдәби-мәдәни процессны тагын да югарырак дәрәҗәгә күтәрүдә әһәмияте бәяләп бетергесез гүзәл дастаннар. Бу исемдәге ядкәрләрнең күбесе – мәгълүм сюжетка корылган фольклор әсәрләре. Шушы һәм башка исемдәге эпос-дастаннар төрки дөнья халыкларында тел-авыз иҗаты булып үскәннәр, көннәр-айлар буе речитатив кулланып әйтелә торган күләмле иҗатны тәшкил иткәннәр, төрле халыкларда әллә ничә версия-вариантта киң таралганнар.**

## ДАСТАН ҖЫРЛАРЫ

Төрки бабаларыбыз тарихының казан татарлары чорына якынлашкан заманнардан алып татар халкында дастаннар, сөйләм белән бәйләнгәнлек чикләрен атлап чыгып, язуга теркәлгәннәр, кульязмалар рәвешендә яисә китапка әверелеп таралганнар. Чичән-импровизатор иҗаты булган традицион сөйләмә дастаннардан һәм шулай ук авторы билгеле әдәби дастан-поэмалардан аермалы буларак, татар халкының мондый төр эпосына карата фәндә «китаби дастан» төшенчәсе кулланыла. Татар китаби дастаннарында фольклор һәм әдәбият традицияләре бергә үрелгән, әлеге укмашканлык үз эченә төрле дәрәҗәдә сюжет-мотивларны да, образлар системасын да, стильне дә һәм башкаларны да ала. Башка халыкларга да билгеле сюжетлы версия-вариантларның иң камил, иң төзекләре татарларда сакланып калган китаби эпос-дастаннар булуы табигый. Халыкта язмачылык традицияләренең ныклы булуы күләмле эпик фольклорның сакланышын тәэмин итүгә уңай йогынты ясаган, эпос-дастаннарның китабилары хәзерге көннәргә дә элекке яңгырашында тулы килеш гаять уңышлы килеп җиткән. Әйтергә кирәк, сөйләмә характерга ия, ягъни сөйләп-көйләп

башкарыла торган эпик әсәрнең халыкның үзе тарафыннан язма-китабига әйләнү процессы хаклы рәвештә цивилизация үсешенең бер баскычы буларак бәяләнә ала.

Татар дастаннары, китабилашып, форма үзгәрткәннәр, ярым-язма, ярым-фольклор әсәре булып үскәннәр. Телдән-телгә күчә-күчә гасырлар кичкәндә югалтулар кичерергә яисә бөтенләй онытылырга мөмкин сөйләмә дастаннар белән янәшә караганда китабиларның камилрәк вариантлар булуын билгеләми калып булмый. Сөйләмә характердагы эпос-дастаннардан китабиларының аермасы шунда: аларда сөйләүче-дастан көйләүченең, ягъни чичәннең эмоциональ чыгышын текст аша гына тоемларга мөмкин, ягъни китаби дастанда эпос-дастанның акциональ өлеше чагылыш таба алмый. Шулай булса да, күчмә төркиләр эпосы өчен характерлы речетатив Идел буе татарлары китаби дастаннарында да элекке функцияләрен үтәгән очраклар да юк түгел. Кайбер дастаннарыбызның шигъри өлешен дутар, думбра белән көйләп әйтү традициясе саклану – шуңа дәлил. Зур әсәрнең кыска өзекләрен – сарын, тулгау, төп каһарманның җыры һәм башкаларны телдән әйтү гадәтенә дә юлыккалыйбыз.

## ЭПИК ҖЫРЛАРДА – ДАСТАННАР ТРАДИЦИЯСЕ

Тора-бара халыкта башкаручы-чичән һәм кабул итүче аудитория катнашыннан гыйбарәт эпос-дастан жанрыннан эпик җырлар (дастан җырлары) аерылып чыга. Татарларда бер яктан китабилык, язма иҗатка омтылыш интенсив төстә өстенлек алган һәм дастаннар китаби булып формалашкан булса, икенче яктан, мәгълүм сюжетлы дастан сюжетыннан этәрелеп, мөстәкыйльлек алуга таба юнәлгән дастан җырлары халык арасында киң тарала. Дастани җырлар татар халык иҗатында гасырлар аша ныклы позицияләр алып урнаша. Бу төр иҗатның дастанның үзеннән башка аерым яши башлавы игътибарга лаек. Информант җырның кайсы дастаннан икәнен үзе үк әйтергә, фабула характерында булса да дастан вакыйгаларын, бу җырның тарихын сөйләп бирергә мөмкин. Шуннан соң ул дастан җырын көйләп күрсәтә.

Кешелек цивилизациясе тарихында форма үзгәртүләр һәрвакыт булып тора һәм функция алыштыру белән бәйле әлеге күренешләр дистәләгән гасырларны колачларга мөмкин. Эпос-дастан ул – халыклар һәм дәүләтләр формалашу процессы белән бергә үзгәрә һәм шулай ук формалаша торган гаять катлаулы күренеш. Сөйләмә дастаннар традициясендә язма-китаби дастаннар формалашу, тора-бара эпос-дастаннардан дастани җырлар дигән иҗат төре үсеп чыгу очрагында да без әлеге дәвамчанлык белән очрашабыз. Структур трансформация аша бүгенге көнгә килеп ирешкән дастан җырларының барысын да – героик эчтәлектәге җырларны да, мәхәббәт дастаннарыннан этәрелгән романтик рухтагыларын да – фольклор эчтәлеккә, эпос-дастаннар сюжетына тугрылык берләштерә.

Дастани җырларның телендә авазлар ягын оештыру, халыкның саф традицион дастанына хас булган аллитерацияле фонетик чаралар куллану кебек ысуллардан читләшү, ә язма әдәбият чараларына мөрәҗәгатьнең исә артуы күзгә чалына. Бу дастани җырларда архаик саф дастан формасы белән әдәби традицияләр ярашу кичергәнлек белән аңлатыла. Әмма дастаннардан аерылып чыгып, үзенчәлекле юнәлеш алып үскән дастани җырлар үзләренең темасы, сюжет, мотивлары, идеясе, сәнгатьчә эшләнеше, типологиясе, яшәү-таралу рәвеше белән халык традициясенә нигезләнгән гомумтөрки эпосына да, шул ук вакытта Борынгы һәм Урта гасыр Көнчыгыш әдәбиятына һәм фольклорына да бердәй якын тора. Дастан җырларның күбесендә силлабиканы классик шигырь системасы – гаруз шигырь төзелеше алыштырган. Ә төрки гарузның, гарәп-фарсы квантатив шигырь төзелеше кагыйдәсенә ияреп, борынгы язма поэзиядә кулланылган метрик система булуы мәгълүм[1]. Димәк, дастан җырлары китаби иҗатка якын тора, бу исә аларның мөстәкыйльлеккә ирешә башлавы нәкъ менә татар китаби дастаннары формалашканнан соң чынга ашкан дигән фикергә китерә. Шул ук вакытта халыкның дастани җырлары силлабикага (халык шигыренә), традицион ысулларга (әйтик, кара-каршы әйтешеп җырлау) таянып үсеш алган очраклар да юк түгел. Кыскалыгы, отып алырга тизлеге дастан җырларының халык арасында тиз таралуын һәм популярлашуын тәэмин иткән.

Дастани җырлар бездә татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә очрый. Халыкның соңгы ярты гасыр чигендәге иҗатын барлаган галимнәр туплаган

[1] Курбатов Х. Ритмика татарского стихосложения. – Казань, б.и., 2005. – С. 8, 20-85.



**Байназар Әлминов. «Идегәй» китабына иллюстрация. 1941 ел**

материаллар арасында дастан җырлары үзенчәлекле урын алып тора. Дастан – үз эченә киң тарихны, бик тирәндә калган борынгылыкны, чордан-чорга күчеп сыналган иң яхшы шигъри традицияләрне сыйдырган гаҗәеп катлам. Озын-озак яшәү дәверендә халык барлыкка китергән эпик әсәрләр рухи тормышта зур урын били. Дөнья фольклорында эпос-дастан – акциональ, вербаль һәм текстуаль кырлары булган иҗат төре, ягъни, гади генә итеп әйткәндә, бу – махсус хәрәкәтләр, интонация, стиль кулланып, билгеле бер тәртиптә башкарыла торган эпик жанр; тел-авыз белән әйтелә-сөйләнә торган сүз сәнгате һәм бербөтен текст буларак кабул ителә торган күләмле әсәр. Жанр буларак барлык тулылыгында ачылсын өчен дастан составындагы җырлар мөһим роль уйнаган. «Түләк», «Бүз егет», «Идегәй», «Кыйссаи авык», «Кыйссаи Сәкам», «Гыйсә улы Амәт», «Шаһсәнәм һәм Гариб», «Хурлуга белән Һәмра», «Алпамыш», «Бүрихан», «Каһарман Катил», «Кисекбаш кыйссасы», «Чура батыр хикәяте», «Күр углы Солтан», ике гашыйкның мәхәббәт тарихын бәян итүдән гыйбарәт романтик рухлы «Таһир белән Зөһрә», «Йосыф китабы», «Сәйфелмөлек», «Ләйлә белән Мәҗнүн» – болар татар халкында төрле вариантларда һәм сөйләмә, һәм китаби-язма формаларда киң таралган дастаннарның тулы булмаган исемлеге. Бу һәм башка эпик әсәрләр татарлар яши торган төрле төбәкләрдә бик борынгы чорлардан ук билгеле булганнар. Дастан каһарманының җыр белән әйткән сүзләре яисә дастан эчтәлегендәге сарын һәм тулгаулар халык хәтеренә ныграк уелган, шул сәбәпле дастани җырлар төп әсәрдән аерым да яшәп китә алганнар булса кирәк. Дастан җырларының күбесе көе белән сакланган булу аерым әһәмияткә ия.

*ИДЕЛ-ЙОРТ*

*– И Идел-йорт, Идел-йорт,*
*Идел эче имин йорт,*
*Атам кияү булган йорт –*
*Иелеп тәзем кылган[2] йорт;*
*Анам килен булган йорт –*
*Иелеп сәлам әйткән йорт;*
*Кендегемне кискән йорт,*
*Керем-коңым юган йорт;*
*Бия сауган сөтле йорт,*
*Кымыз эчкән котлы йорт;*
*Идел-Җаек арасы*
*Елкы белән тулган йорт.*

**(«Идегәй» дастаныннан; 2014 елда Самара өлкәсенең Камышлы районы Дәүләткол авылында яшәүче Мөхетдинова Рәйханә Гайнетдин кызыннан (1932 елгы) Л. Мөхәммәтҗанова язып алды).**

*БҮРИХАН*

*Бүрихан ул хан иде,*
*Башында ла тастар[3] иде,*
*Бүриханны үлтерергә*
*Түрә мырза[4] кул бирде.*
*Бүрегем юк башымда,*
*Туганым юк каршымда,*
*Бер туганым булса иде,*
*Елар иде каршымда.*
*Бүрихан тун кигән лә,*
*Якасы кондыз иде,*
*Бүриханга көн ярашмый,*
*Койрыклы йолдыз иде.*

**(«Бүрихан» дастаныннан; 2016 елда Чиләбе өлкәсе Нязепетровский районының Нязепетровск шәһәрендә яшәүче Мугафин Гафур Мугаф улыннан (1933 елгы) Л. Мөхәммәтҗанова язып алды).**

*МӘРҖӘН СЫЛУЫМ*
*(Алыпмәмшән)*

Лап-лоп басканда-й аюмы иң-әй?
Шул зинданнарга килгәнме идең-әй?
Мәрҗәнсылуым, Мәрҗәнсылуым,
Ай-һай көннәр-әй,
Үтте төннәр-әй.

**(«Алпамыш» дастаныннан; 2019 елда Азнакай районы Иректе авылында яшәүче Әхмәтшина Сәвилә Юныс кызыннан (1937 елгы) Л. Мөхәммәтҗанова язып алды).**

## ДАСТАН ҖЫРЫ – ЭПОСНЫҢ ШИГЪРИ КАЙТАВАЗЫ

Татар китаби эпос-дастанының ике канаты бар: бер канаты – төрки эпик традицияләр, ә икенчесе – борынгы Көнчыгыш әдәбияты. Дастаннарыбыз гасырлар дәвамында шушы ике канатка таянып үскән һәм формалашкан. Татар дастаны әдәбиятка якынаю кичергән, әмма фольклор белән кире бәйләнешен һичкайчан югалтмаган. Фольклор белән кире бәйләнеш төшенчәсенең гаять киң кырлы булуын истә тотарга кирәк. Фольклор

[2] Тәгъзим кылу – олылау.
[3] Тастар – баш киеме.
[4] Мырза – морза.

белән кире бәйләнеш ул – индивидуаль автор әсәреннән башлангыч алып, фольклорга күчкән – фольклорлашкан әсәрдә; фольклор әсәрләренең аерым автор тарафыннан үзгәртелүе-эшкәртелүе нәтиҗәсендә кабат торгызылган әсәрдә; турыдан-туры язмача барлыкка килгән фольклор сюжетлы ядкәрләрдә эпик мотивлар кулланылу традициясендә, дастан сюжетының халыкта фабула характерында булса да яшәп килүендә һәм, ассызыклап әйткәндә, дастан җырларының мөстәкыйль жанр формасын алу дәрәҗәсенә җитеп, дастаннан аерым җыр буларак яшәвендә һәм башкаларда чагылыш таба. Хәлбуки эпос-дастан жанрын бүгенге фән-техника һәм компьютер чорында актив яши торган иҗат төре дия алмыйбыз. Әмма халык иҗаты белән бәйләнешнең булуын чагылдыра торган дастани җырлар – эпос жанрының татар традицион мәдәниятендә тәгаен урын биләгәнлеген раслый торган күренеш. Дастан җырларының соңгы чорларда да халыкта яшәве эпосның бүгенге көннәргә килеп җитүен күрсәтә.

Фольклорда һәм гомумән әдәбиятта билгеле бер жанрның вакытлар үтү белән юкка чыгуы – табигый хәл. Дастаннар иҗат итү традициясенең бүгенге көндә бөтенләй сүнгән булуы шушы закончалык белән аңлатыла. Жанрның сүрелүенә китергән сәбәпләр күп төрле. Биредә төп фактор татарларның төрки дөньядан аерылып яшәве булса кирәк. Шулай ук Идел буе татарларына ислам диненең бик иртә көчле тәэсир ясап, фольклорда моңа кадәр яшәп килгән сюжетларның кысрыклануы һәм дини мотивларның өстенлек алуы да төрки эпос традицияләренә корылган дастаннарның элекке әһәмияте югалуга китергән. Болардан тыш заманча шәһәр мәдәнияте, оригиналь әдәбиятның көчәеп, үсеп китүе, гарәп язуын башка язу системасына алыштыру, фән-техника казанышлары һәм башка тәэсирләр халык иҗатыннан эпос жанрын кысрыклап чыгарган. Төрле тарихи шартларда татарларның таралып урнашуы, территориаль бөтенлекнең булмавы, утрак тормыш рәвеше бер яктан сөйләмә дастаннар иҗат итү традициясен сүндергән. Әмма шул ук вакытта татарларда, аерым алганда Идел буе татарларында, бер яктан, жанрның китаби төре үсеш алган, икенче яктан, кайчандыр халык ихтыяҗын канәгатьләндереп килгән популяр иҗат – сөйләмә характерда башкарылган, эпосның иң тәэсирле, иң тетрәндергеч өлешен тәшкил иткән дастани җырлар яшәвен дәвам иткән һәм итә. Дастан җырлары соңгы елларда халыкта киң таралган жанр дип әйтеп булмаса да, белгечләр тарафыннан соңгы елларда аларның халыктан шактый күп язып алынганлыгын да танымый булмый. Гомумән, дастан җырларының татарлар яши торган төбәкләрдә әле дә очрап торуы үзе үк бик зур казаныш.

Димәк, дастан җырлары, кагыйдә буларак, информантка күләмле эпик сюжет аша таныш, алар кайсы да булса бер мәгълүм эпос-дастан сюжеты белән тыгыз бәйләнештә торалар. Дастандагы теге яисә бу персонажның башкарган җырыннан, яисә әсәрнең иң тәэсирле урыныннан гыйбарәт телдән көйләп әйтелә торган шигъри текстларны дастан җыры (дастани җырлар, эпик җыр) дип атыйлар.

## КЫЙММӘТЛЕ МИРАСЫБЫЗ ТАНЫЛСЫН!

Дастан җырлары гасырлар дәвамында катлаулы юл узганнар, әмма онытылмаганнар. Дастаннарның халыкта иң популярлары бүгенге көндә нәкъ менә эпик җыр, ягъни дастан җыры рәвешендә яши. Дастан җырлары татарларда эпос-дастан жанрының кайчандыр халык телендә актив иҗат булганлыгын дәлилли. Татар дастаны сюжетыннан аерым җырларның бүгенге көндә дә фольклорда очрап торуы эпосның халыкта җитди урын биләве хакында сөйли. Дастан җырларында югары идеяләр һәм сәнгатьчә матурлык халкыбызда эпик культура традицияләренең дәвамлы булуын күрсәтә. Дастан җырларының бүгенге көннәрдә дә халыктан язып алынуы – татарларда дастан жанрын танытуга өлеш кертүе белән кыйммәт.

Татар халык иҗатында мәхәббәт дастаннары билгеле бер тарихи чорда әдәбиятка якынаю кичерсәләр, каһарманлык дастаннары тарихи җыр, социаль эчтәлекле бәет яисә тарихи елъязмага әверелә бару күренеше мәгълүм. Шушындый трансформация шартларында дастан җырларының эпос белән бәйле, әмма бу жанрдан инде аерылган, мөстәкыйль әсәр буларак башкарылу тенденциясен алган ядкәрләр дип күрсәтү дөрес булыр. Информантлар бу төр иҗатны, әйтик, «Таһир-Зөһрә»дән җыр, «Таһир җыры», «Бүз егет», «Сәйфелмөлек җыры» дигән исемнәр белән тәкъдим итә. Җыр мәгълүм дастан герое исеме белән йөртелмәгән һәм информант җырның тарихы хакында хәбәрдар булмаган очракта да, махсус тикшеренүләр үткәргәннән соң аның дастан составындагы җыр белән аваздаш булуы ачыкланса, бу ядкәр дастан җыры категориясендә кара-

ла. Укучылар игътибарына туплап бирелә торган дастан җырлары – үзенең лирик табигатьле булуы, отып алырга һәм башкарырга җиңеллеге белән халык хәтеренә шактый тирән уелган дастаннар кайтавазы. Соңгы чорда алар, эпос-дастан жанры чикләрен атлап чыгып, халыкта мөстәкыйль жанр буларак яши башлаганнар, әмма үзенең асылы белән бу җәүһәрләр – татарларның эпос-дастан жанрын хәтерләтеп тора торган кыйммәтле мирас.

### *СӘЙФЕЛМӨЛЕК ҖЫРЫ*

*Сәйфелмөлек китте диңгез буена*
*Карамады әнисенең сүзенә;*
*Ник карасын әнисенең сүзенә,*
*Гашыйк булган җен-падиша кызына.*
*Төштә күргән пәри кызның сурәтен,*
*Илен каян, атын кемнән сорасын.*
*Пәри кыз елмаеп баккан йөзенә,*
*«Син минеке!» – диеп әйткән үзенә.*
*Гашыйклыкның угын аткан күзенә,*
*Башын куеп, имеш, яткан тезенә.*
*Азмы Сәйфелмөлек кебек егетләр,*
*Гашыйклыктан диваналар кебекләр?*

**(«Сәйфелмөлек» исемендәге мәгълүм мәхәббәт дастаны сюжетына нигезләнеп туган бу җыр татарларның мишәр этник төркеме вәкилләре яшәгән төбәкләрдә һәм Себер якларында киң таралган; иң беренче язып алынган вариант Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә саклана, җыр 1955 елда Ф.В. Әхмәтова тарафыннан Ишмаметов Хафиздан язып алынган. «Татар халык иҗаты Дастаннар» (Казан, 1984. Төзүчесе Ф. Әхмәтова) китабында «Сәйфелмөлек» дастаны сюжетына бәйле әлеге җыр тексты, аның тарихи нигезләре, басма, кулъязма чыганаклары, җырның көй вариантлары турында тулы мәгълүмат бирелгән (Б. 360-362)).**

### *КИРУГЛЫ ҖЫРЫ*

*Биек, биек, биек таудан үтәрмен(әй),*
*Хәрәм алып максадыма җитәрмен(ау);*
*Арап, бире килмә, сине атармын(әй-гей-гей),*
*Синнән курыккан әнисеннән тумасын.*
*Бүген ишетең Кируглының җырын(ый),*
*Төрле Арап, күрче, майдан тузына(у);*
*Җиңгәм өчен алдым, Арап, кызыңны(и),*
*Синнән курыккан әнисеннән тумасын.*

**(«Күр углы» эпос-дастаныннан; Казан дәүләт консерваториясе экспедициясе тарафыннан 1998 елда Әстерхан өлкәсе Приволжск районы Татар Башмагы авылында яшәүче Сәфәров Сәләхетдин Җәләлетдин улыннан (1934 елгы) язып алынган. Түбәндәге китаптан алынды: Памятники татарского народного музыкально-поэтического творчества. Вып. 1. Песни Астраханских татар. Әстерхан татарлары җырлары. Сост. и нот. транскр. Е.М. Смирновой и Н.Г. Гайнуллиной. – Казань: Казанская консерватория, 2007. – С. 222-223).**

### *ТАҺИР-ЗӨҺРӘ*
### ***(Кызыл алма аягың...)***

*Кызыл алма аягың,*
*Саф көмештәй сөягең;*
*Гәүһәре якут беләгең,*
*Күреп күңелем булармы?*
*Күп сар булган күргәли,*
*Риза булган үлгәли;*
*Таһир җаның килгәнтур*
*Гөлйөзеңне күргәли.*

**(«Таһир-Зөһрә» дастаныннан; Төмән өлкәсе Тобол районының Лаймтамак авылында яшәүче Бәхтиева Сәрвәрдән (1900 елгы) 1971 елда магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм М. Кадыйрова тарафыннан язып алынган. Текст түбәндәге китапта басылган: Кадыйров И.Ш. Татар халкының туй җырлары. Себер ареалы. – Казан: ТӘһСИ, 2021. – Б. 92).**

### *ҖЫР*
### ***(Таһир белән Зөһерәне...)***

*Таһир белән Зөһерәне суга агызганнар*
*Сандык ясап тактадан,*
*Исән булсак, бер кавышырбыз әле.*
*Без суларга акмаган.*

**(«Таһир-Зөһрә» дастаныннан; 2019 елда Азнакай районы Иректе авылында яшәүче Әхмәтшина Сәвилә Юныс кызыннан (1937 елгы) Л.Х. Мөхәммәтҗанова язып алды).**

### *БҮЗ ЕГЕТ*

(Агачның башын киссәң, төбе калыр...)
Агачының башын киссәң, төбе калыр,
Икәвенең бере үлсә, бере калыр,
Ялгызакның үзе үлсә, нәселе калыр,
Менәр аты, кигән киеме яуга калыр.
Заманыннан күп заманнар үтте дияр,
Яңа ярлар иске ярны оныттырыр.
Яңа ярлар яулык белән аш китерер,
Иске ярлар кара күздән яшь китерер.
Агыйделнең ярларына дулкын кагар,
Дулкыннары кире киткәч, комы калыр.
Яры белән торганнарның улы калыр,
Ялгыз башның бу дөньяда кеме калыр?

**(«Бүз егет» дастаныннан; 2017 елда Чиләбе өлкәсе Уй районының Әмин авылында яшәүче Биккулова Фәнүзә Хаҗиәхмәт кызыннан (1959 елгы) Л.Х. Мөхәммәтҗанова язып алды. Информант җырга керешер алдыннан шундый мәгълүмат бирде: «Әнкәй «Бүз егет» дип әйтә иде моны, борынгы бу. Китаплары да бар иде аның. Китаптан карап әйтә иде»).**

# ХАЛКЫБЫЗ ИҖАТЫНДА – *асыл тамырыбыз*

***(Фольклорчы галим Х. Мәхмүтовның тууына 90 ел тулу уңаеннан)***

*Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,*
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре*

**Акыл ияләре адәм баласының дөньяда якты эз калдырып яшәвен хуп күрәләр, тереклекнең нәкъ менә шундыенда тирән хикмәт табалар. Чыннан да, гомернең кыйммәте еллар саны белән генә билгеләнми, кылган эшгамәлеңнең асылы, куйган хезмәтеңнең башкаларга кирәкле булуы да гомерне озынайта, исемеңне киләчәк буыннарга алып бара. Әгәр Аллаһы тарафыннан бирелгән озын гомер мул җимешле булса, күпкырлы һәм күләмле эшең аша исемеңне күпләр белеп, сиңа хөрмәт белән караса, бу инде яшәвең бушка китми, узган юлыңда җуелмас эзең кала дигән сүз. Кеше өчен бәхет-сәгадәткә ирешү юлы нәкъ менә шул түгелме соң?**

Филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, Республиканың Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Хуҗиәхмәт Мәхмүтов – безнең арабызда үзенең яше белән дә, башкарган эшләре белән дә олуг ихтирамга лаек шәхесләрнең берсе иде. Исән булса, 2023 елның 15 февралендә 90 яшьлек зур юбилеен билгеләгән булыр иде ул. Сиксән сигез яшенә җитеп бакыйлыкка күчкән аксакал галим – үз гомеренең алты дистә елдан артыгын чын мәгънәсендә фидакарь фәнни эшчәнлеккә багышлаган шәхес.

Татар милләтенә Хуҗиәхмәт аганы халкыбызның җырга-моңга, күркәм гореф-гадәтләргә ифрат бай вә гүзәл табигатьле Мамадыш төбәге биргән. Ул 1933 елның 15 февралендә Түбән Ушмы авылында дөньяга килгән, шушында җидееллык, ә район үзәге Мамадыш шәһәрендә урта мәктәп тәмамлаган. Булачак галим үзенең хезмәт юлын да туган җирендә башлый. Өлгергәнлек аттестаты алгач, ике ел Көек Ерыска җидееллык мәктәбендә математика һәм физика укыта.

Тырышлыгы, белемгә омтылучанлыгы тиздән аны мәркәзебез Казанга, университетның тарих-филология факультетына алып килә. Татар телен, әдәбиятын, тарихын максатчан өйрәнеп, яшьтән үк

төп игътибарын халыкның рухи хәзинәләренә юнәлткән җитди холыклы егет 1958 елда университетны кызыл дипломга тәмамлый.

Озын хезмәт юлының 50 елга якыны гел бер урын – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән бәйләнгән. Ул әле студент елларында ук, вакытлы хезмәткәр сыйфатында, әлеге институт оештырган фольклор экспедицияләрендә катнаша, андагы галимнәр белән берлектә халык җәүһәрләрен җыю, туплау белән шөгыльләнә башлый.

Университетны тәмамлап, елдан артык шушы абруйлы уку йортының татар теле һәм әдәбияте кафедрасында өлкән лаборант, соңрак Буа районының «Яңа юл» газетасында әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркәтиб, бүлек мөдире вазифаларын башкарып, шактый хезмәт тәҗрибәсе туплагач, 1966 елда Х. Мәхмүтов әле студент чагында ук юл салган Тел, әдәбият һәм тарих институтына (хәзер Галимҗан Ибраһимов исемен йөртә) янә әйләнеп кайта. Халык иҗатына мәхәббәте, хикмәтле фольклор дөньясындагы бетмәс-төкәнмәс рухи байлык белән кызыксынуы аны Институтның халык иҗаты бүлегенә бәйли. Биредә ул аспиранттан алып баш фәнни хезмәткәргә кадәр үсү юлы үтә, «Татар халык табышмаклары» дигән темага кандидатлык, халкыбызның афористик иҗатына багышланган докторлык диссертациясе яклый. Ул инде 1970 елдан ук институтның Гыйльми советы, 1981 елдан – диссертацияләр яклау советы әгъзасы. Байтак еллар биредә профсоюз һәм партия оешмаларын җитәкли, Мәгариф, югары мәктәп һәм фәнни учреждениеләр хезмәткәрләре профсоюзының VII съездында делегат булып катнаша.

Институтта эшләү дәверендә галим татарлар яшәгән төрле төбәкләргә оештырылган күпсанлы фәнни экспедицияләрдә катнаша, үз заманындагы халык авыз иҗатын бөртекләп җыеп, аларны тәртипкә китереп, җыентыклар төзи, матбугатта бастырып чыгара. Х. Мәхмүтов – 30 китап, меңгә якын мәкалә авторы. Республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган 13 томлык «Татар халык иҗаты» җыелмасын әзерләүдә аның өлеше зур. Ул бу фундаменталь басманың редколлегия әгъзасы, биш томының фәнни мөхәррире, «Табышмаклар», «Мәзәкләр», «Мәкальләр һәм әйтемнәр» томнарын төзүче, аларга кереш мәкалә һәм фәнни искәрмәләр язучы.

Борынгы ядкәрләребездә теркәлеп калган рухи кыйммәтләрне барлап, фәнни монографияләр чыгару – галим эшчәнлегенең аеруча әһәмиятле биеклеге. Ул бик күптәнге чорларга караган мәкаль-әйтемнәрне һәм башка афоризмнарны җентекле өйрәнә, аларның бүгенге көнгәчә үсеш-үзгәрешен күзәтеп, тирән анализлый, бу төр әсәрләрнең асыл хикмәтен, нәзберек шигъриятен нечкә тоемлап яза. Х. Мәхмүтовның «Мәңгелек ядкәр» (2002), «Борынгылар әйткән сүзләр» (2002) кебек монографияләре – шушы өлкәне колачлый торган зур хезмәтләре. Болардан тыш, татар халкының фольклор мирасын ачуга галимнең уннарча саллы мәкаләләре багышланган. Мондый характердагы тикшеренүләре төрле хрестоматия һәм фәнни җыентыкларга кертелгән.

Табышмакларның жанр үзенчәлеген өйрәнүгә багышланган «Кечкенә дә төш кенә» (1980), халык календаре серләренә төшендерә торган «Ел тәүлеге – 12 ай» (1991), фольклорда әдәп-әхлак мәсьәләләренә багышланган «Язылмаган кануннар» (1995), халык сөйләмендә очрый торган сүз-гыйбарәләрнең хикмәтен, тарихын, нинди уңай белән әйтелүен тәфсилле аңлатып-төшендереп, сүз эченә яшерелгән энҗе бөртеген күрсәтеп бирә торган «Канатлы сүз – хикмәтле сүз» (1999), «Гыйбарәләр тарихыннан сәхифәләр» (2008), «Изге китаплар кайтавазы» (2012) кебек китаплары фәнни-теоретик яктан да, киң катлам укучыларының гамәли ихтыяҗын истә тотып язылган булуы белән дә гаять әһәмиятле. Галимнең тырышлыгы, иҗат мөмкинлекләре һәм язу куәсе һәркемне сокландырырлык: аның каләменә гыйльми дә, үтемле һәм кызыклы да итеп язу сыйфаты хас.

Х. Мәхмүтовның хезмәтләре арасында әле алда телгә алынмый калганнары да шактый. Монографияләрдән башка, ул – «Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр: ике томда» (1974, 1975), «Татар фольклоры жанрлары» (1978), «Татар фольклорында социаль мотивлар» (1986), «Поэтика татарского фольклора» (1991), «XX гасырның күренекле тюркологы Рәшит Рәхмәти Арат» (2001), «Хәмит Ярми: галим һәм шәхес» (2004), «Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр» (3 нче том, 2005), «Халык җырчысы Абдулла Кротов» (2010) һәм башка җыентыкларның я җитәкчесе, я төзүчесе-мөхәррире, я төп авторларыннан берсе.

«Энҗе чәчтем – энҗе җыям» дигән гомуми исем белән мәктәп-гимназияләр өчен татар халык иҗатыннан уку ярдәмлеге буларак чыгарылган 9 китапның дүртесе шулай ук аның тарафыннан әзерләнгән.

Галим буларак, Х. Мәхмутовның эшчәнлеге күп еллар дәвамында фәнни конференцияләрдә чыгышлар ясау һәм яшь галимнәргә гыйльми юнәлеш бирү белән тыгыз аралашып бара. Казан, Новгород, Тбилиси, Алмата, Бишкәк, Анкара һәм башка шәһәрләрдә уздырылган халыкара конференцияләрдә ул укыган докладлар җитди фикерле булулары белән игътибарны җәлеп итә. Галим җитәкчелегендә 2 докторлык, 5 кандидатлык диссертациясе якланган. Ул ун ел дәвамында Казанның филология профильле югары уку йортларында (ул еллардагы исеме белән телгә алганда – КДУ, КДПУ һәм башкалар) Дәүләт аттестация комиссиясе рәисе булып эшләде.



Хуҗиәхмәт Мәхмүтов

Галим үзенең басма хезмәтләре, фәнни конференцияләрдә һәм матбугаттагы даими чыгышлары белән татар дөньясына әйбәт таныш. 1970 нче еллардан бирле аның исеме милләттәшләребезгә ул даими катнаша торган «Тел күрке – сүз» радиотапшырулары аша да ирешеп торды.

Х. Мәхмүтовның киң кырлы гыйльми, әдәби, публицистик һәм педагоглык эшчәнлеге, алда саналган мактаулы исемнәрдән тыш, Татарстан Республикасының Мактау Грамотасы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты, «Хезмәт ветераны», «Казанның 1000 еллыгы истәлеге», «Фидакарь хезмәт өчен» медальләре, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы президиумының, Татарстан Фәннәр академиясенең, Мәгариф, югары мәктәп һәм фәнни учреждениеләр хезмәткәрләре профсоюзының Республика комитеты (РСФСР) Президиумы Мактау грамоталары, Татарстан Президенты Р. Миңнехановның «Рәхмәт сүзе» белән бәяләнгән.

Хуҗиәхмәт аганың иҗаты, фәнни хезмәтләре, кылган гамәле, тапкыр сүзе, хәтта кайбер очракларда дәшми калуының тирән мәгънәгә ия булуы хакында гына да озак сөйләргә мөмкин булыр иде. Яшәешенең төп мәгънәсен халык иҗатын барлауда, өйрәнүдә күргән асыл зат ул. Халкыбызның ерак үткәненә багып, бик тирәннән җәүһәрләр табуы, аларны өскә күтәреп, кабат балкыта алуы галимнең гомерен мәгънәле иткән.

# Мөслимчә «ЗӘҢГӘР ШӘЛ»

*Сәвия СӘМИТОВА,*
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан милли тикшеренү технологик университеты доценты*



**2022 елның 9-22 ноябрь аралыгында узган театр коллективларының XXII «Идел-йорт-2022» төбәкара конкурсында пьесалар сайлауга зур игътибар бирелүе күзгә ташланды: соңгы еллардагы драматургия үрнәкләре булган Исламия Мәхмүтованың «Мәхәббәт чишмәсе», Айгөл Әхмәтгалиеваның «Сагынган чакларымда» әсәрләреннән башлап, татар милли драматургиясенең камил өлгеләре – Галиәсгар Камалның «Банкрот», Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл» драмаларына кадәр куелды.**

Фестиваль кысаларында күрсәтелгән спектакльләрдән Мөслим халык театры тарафыннан сәхнәләштергән «Зәңгәр шәл» мелодрамасын миңа да карарга мөмкинлек туды.

Камал театрының визит карточкасы булган «Зәңгәр шәл»не профессиональ һәм халык театрларның һәрдаим сәхнәләштереп торуы пьесаның халык тарафыннан яратылуы хакында сөйли. Бер уңайдан театрның сәнгать җитәкчесе Эльвира Гәрәева фикерен дә җиткерәсе килә: «Бу пьесага мөрәҗәгать итүебез очраклы түгел. Без театрыбыз белән һаман да классикага игътибар бирәбез, чөнки татарның үткәне һәм бүгенгесе арасында салынган күпер вазифасын башкарган классик әдәбият беркайчан да актуальлеген җуймый. Халкыбызның драматургия үсешендә Мирхәйдәр Фәйзи традицияләрен дәвам итүче Кәрим Тинчурин безнең өчен бик якын. 2017 елда аның «Сүнгән йолдызлар» драмасы белән «Идел-йорт» фестивалендә Гран-прига ия булган идек. Быел да кыйблабыз булган классик әдәбияттан тайпылмыйча, тамашачылар һәм жюри игътибарына Кәрим Тинчуринның аталы «Зәңгәр шәл»ен тәкъдим итәргә булдык. Бу минем күптәнге хыялым иде. Моңа ышанычымны быел гына безгә режиссер булып килгән Синара ханым Яббарова тагын да арттырды. Шул рәвешле спектакль сәхнәдә».

Спектакльнең пьесадан читкә тайпылмыйча: «Һаваларда йолдыз, суларда кондыз, Газизәкәй балдыз, елама, калдырма ялгыз...», – дип «Газизәкәй балдыз» җырыннан башлануы ук моңга төрә, күңелнең әллә нинди нечкә кылларына тиеп, ниндидер сагыну хисләре тудыра һәм үткәннәргә борылып карарага мәҗбүр итә. Гыйшык утында янган, мәгълүм сәбәпләр аркасында сөйгәненнән еракта төрле җәбер-золымнарга түзеп яшәгән Мәйсәрәнең бөтен шатлыгы да, юанычы да шул җыр.

Спектакльдәге аерым җыр булсынмы, күмәк булсынмы – барысының да техник яктан камил башкарылуына гаҗәпләнеп тә куясың – югыйсә, профессионаллар түгел бит. Алга таба аларның музыкальлеге генә түгел, актерлык сәләте дә, сәхнә теленең бик камил булуы да ачыклана. Мәйсәрә ролен башкаручы Гүзәл Галиеваның җыр сәнгатендә һәвәскәр түгел, бәлки, чын мәгънәсендә, оста икәнлеге ачык күренә.

Гүзәл Галиева һәм Булат ролен башкарган Илфират Зәйниев сәхнәдә мәхәббәт тарихының хисси ягын чын эмоцияләргә төреп күрсәтә дә, сүзләр һәм җыр аша сөйләп бирә дә алды. Тамашачы спектакль ахырынача геройларга «ышанып», аларга теләктәшлек белдереп, кирәк чакта ихластан борчылып, кирәк чакта самими шатланып утырды. Бу башкаручыларның осталык дәрәҗәсенә бәя. Театр сәнгатендә Станиславскийның данлыклы гыйбарәсенә иярепп: «Ышанам!», – диясе килде.

Ишан һәм аның хатыннарын башкарган артистларга да игътибарны юнәлтәсе килә. Ишан образын тудыруда Равил Тимкин бик кызыклы



позицияне сайлаган. Кәрим Тинчурин бу образны замана чире, социаль проблема чагылышы буларак тәнкыйть угында тотып, сатирик рәвештә тасвирласа, артист яңа штрихлар ярдәмендә заманчалаштырырга тырышкан. Шул рәвешле ишанга карата ниндидер нәфрәт яки чирканчык хисләр кичермисең, комик образ буларак кына кабул итәсең. Хәзрәтнең хатыннарын башкаручы артистларның образлар характерын тирәнтен аңлап эш йөртүләре күзгә ташлана, гәрчә бераз гына профессиональ башкаручыларга иярү сиземләнсә дә. Әмма мин моны тискәре күренеш димәс идем, чөнки Камал театры бу спектакльне уйнау өлгесен берничә буын артистлары тарафыннан раслап, милли театр дәрәҗәсенә күтәрде.

Спектакльдә күмәк уеннар, биюләр байтак. Аларны башкару хореограф Индира Тимкина, музыкаль бизәлеш авторы Илшат Галиев эшчәнлегенең һәм дә артистларның зур тырышлыгы һәм сәләте нәтиҗәсе дип уйлыйм.

Декорацияләргә килгәндә, драма нигездә өч җирлектә бара: беренчесе – Мәйсәрәнең торган ишегалды, икенчесе – ишан йорты һәм өченчесе – урмандагы качкыннар яшәгән урын. Алар барысы да әсәрнең эчтәлеген ачарга, шул чор мохитен тудыруга ярдәм итә. Йорт аллары булсынмы, урман алачыгымы – барысы да тиешенчә ясалган, сәхнә таләпләренә җавап бирә.

Персонажларның кием-салымы да чор атмосферасына тулаем туры килә. Бу очракта Камал театры куелышына иярү юк, костюмер Римма Йосыпова үзенең күзаллавы буенча татар милли киеменең үзенчәлекләрен истә тотып, кызларга гади генә күлмәкләр һәм яулыклар, ир-атларга җиләннәр кидерткән. Ишанның хатыннары да үз дәрәҗәләренә туры килгән, зәвыклы һәм бай киемнәрдән.

Халык театры булуга карамастан, спектакльдә катнашучыларның саны шактый һәм аларның төрле яшьтәге актерлар булуы күзгә ташлана. Араларында мәдәният йорты хезмәткәрләреннән гайре төрле профессия вәкилләре бар: гомуми белем бирү һәм сәнгать мәктәбе укытучылары да, музей һәм китапханә белгечләре дә, районның башка хуҗалык оешмалары хезмәткәрләре дә. Бу гаять матур күренеш. Көн дәвамында җәмгыятьнең төрле тармагында хезмәт куйганнан



соң, театрга җыелып репетицияләр үткәрәләр икән, бу артистларның татар сәнгатенә мөнәсәбәтен чагылдыра, халкыбызның киләчәгенә битараф түгеллеген исбатлый.

Гомумиләштереп әйткәндә, бу спектакль Мөслим районы житәкчеләре, район мәдәният йорты, театрның сәнгать житәчесе Эльвира Гәрәева, режиссер Синара Яббарова һәм барлык артистларның күмәк хезмәт җимеше. Минем карашымча, бу спектакль шушы конкурс һәм Мөслим районы мәдәният йорты белән генә чикләнмәсен иде, аны башка районнардагы тамашачыларга да күрсәтәсе иде.

«Зәңгәр шәл» драмасы тамашачыга эмоциональ һәм сәнгати рәхәтлек бирә. Шуңа да аны һәр буын үзенчә яңартып уйный, яратып карый. Һәр кеше үзенең күңелендә булган хисләре аша үткәреп кабул итә, рәхәтләнеп көлә, рәхәтләнеп елый, соңыннан да тиз генә онытмый, кабат-кабат кайтып искә ала.

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан





# Су юлы күрсәтү

**(Сәхнәдә кую өчен)**

*Гөлфия МӘГЪСҮМОВА,*
*Тәнзилә ВӘЛИЕВА,*
*Арча районы Ташкичү авылы клубы хезмәткәрләре*

**«Су юлы күрсәтү» – татар халкы йолаларының берсе. Кияү йортына төшкән көнне, туй мәҗлесенә кадәр, я булмаса, икенче көнне яшь килен көянтә-чиләк белән су алып кайтырга тиеш. Чөнки су – яшәү чыганагы. Яшь килен – учак хуҗабикәсе. Килен башка авылдан төшсә дә, үз авылыннан булса да, беренче мәртәбә суга үзен генә җибәрмиләр. Йола буенча аны егетнең кыз туганнары озата бара. Килен судан кайткач аларга үз бүләкләрен – чиккән кулъяулыклар өләшә...**



Килен ак алъяпкычын тагып, көянтәгә чиләкләрен асып, яшь кияү белән парлап, я булмаса кызлар, апалар белән чишмәгә суга китә. Аларны туйда катнашучылар гармуннар, җырлар белән озата бара.

Яшь киленгә су юлын
Күрсәтү – изге бурыч,
Туры, дөрес юлдан гына,
Килен, йөрергә тырыш.
Һәр көн саен таң яктысы
Сирпеп битеңне үбәр,
Син барасы су юлына
Зөһрә йолдыз нур сибәр.
Ай бизәкле чиләкләрең
Таң суында йөзсеннәр,
Сандугачлар, сайрый-сайрый,
«Уңган килен!» – дисеннәр.
Мөлдерәмә тулы булса
Һәрвакытта чиләгең,
Зур бәхеткә ирешерсең,
Кабул булыр теләгең.

* * *

**1 нче кыз:**

– Менә килеп тә җиттек.

**2 нче кыз:**

– Әй, кызлар, балачакта шушы чишмәгә йөгереп төшә идек тә, салкын суын эчә идек. Салкын тию дигән нәрсәне белми дә идек.

**3 нче кыз:**

– Без дә яшь киленнәрнең, кызларның чишмәгә суга баруларын читән артына качып карап кала торган идек.

**1 нче кыз:**

– Кызлар, әйдәгез, киленне беренче үзебез сынап карыйк.

**2 нче кыз:**

– Әйдәгез, киленне бер биетеп тә алыйк.

*(Такмак әйтелә, килен бии.)*

Бие әле, бие әле, биегәнең юк әле,
Сине матур бии диләр, биетеп карыйк әле.

**1 нче кыз:**

– Афәрин, булдырасың!..

**2 нче кыз:**

– Кызлар, киленнең чишмәгә куеп калдыра торган чиккән сөлгесе бар. Шуның белән «Сөлгеле капка» уенын уйнап алыйк.

**3 нче кыз:**

– Әйдәгез, тезелегез. Кем ялгыз калды?

*(Ялгыз калган кеше «капка» алдына баса, башкалар аңа җырлый.)*

Аклы ситса күлмәгеңне
Өстәлләрдә кистеңме?
Йөзең гөлләргә охшаган,
Гөл эчендә үстеңме?
Сөлгеле капка алдында
Йөрисең дә йөрисең.
Тавык булып кыткакламый
Бу капкадан кермисең.

*(«Капкадан» кермәкче була, кертмиләр, җәза бирелә, тавык булып кыткаклап җәзасын үти, үзенә ошаган кешене алып, артка баса. Ялгыз калган кеше «капка» алдына баса, уен шулай дәвам итә).*

Агыйделнең аръягында
Үсә микән бөрлегән?
Кайсыгызны сайлап алыйм –
Барыгыз да бер дигән?
Сөлгеле капка алдында
Йөрисең дә йөрисең.
Бер матур җыр җырламыйча
Бу капкадан кермисең....



**1 нче кыз:**

– Кызлар, әйдәгез, икенче уен уйныйбыз.

**2 нче кыз:**

– Туктагыз әле, тамак кипте, килен куллрыннан су эчик.

*(Шау-шу. Килен чишмәдән су ала.)*

**3 нче кыз:**

– Беренче булып киленнең суын мин авыз итәм. (Килен су бирә.) Нинди саф су! Шушы чишмә суы шикелле мәхәббәтегез дә саф булсын.

**1 нче кыз:**

– Мин дә авыз итим әле. Суыгыз янган йөрәкләргә шифа булсын.

**2 нче кыз:**

– Кызлар, килен суны түкми алып кайта алыр микән?

**3 нче кыз:**

– Нишләп түксен?! Әмәле бар бит аның. Агач яфрагын чиләгендәге суына салсаң, тамчысы да төшми.

**1 нче кыз:**

– Мә әле, килен, менә шушы көмеш тәңкәне, чишмә юллары бетмәсен, онытылмасын дип, теләгеңне теләп, чишмәгә сал.

*(Килен чишмә суын чиләкләренә тутырып алганнан соң, көмеш тәңкәне чишмәгә ташлый.)*

**2 нче кыз:**

– Кызлар, җырладык, биедек, килен кулларыннан шифалы чишмә суларын эчтек... Туктагыз әле, кызлар, килен бит безгә чишмә юлын күрсәткән өчен, чиккән кульяулык бирергә тиеш – бар микән?

**Килен:**

– Бар, кызлар, бар, менә шундый кульяулыклар чиктем сезнең өчен. Кайтуга таратам.

**1 нче кыз:**

– Килен уңган безнең... Өйдә әти-әниләр көтә. Тизрәк кайтыйк.

**2 нче кыз:**

– Әйе. Килен алып кайткан суны беренче булып каенана белән каената эчәргә тиеш.



Атларыбыз, атларыбыз,
Канатлы чакларыбыз,
Безнең дә бер булыр икән
Киленле чакларыбыз.
Китмәскә килерең булсын,
Йөзең гел көләч булсын,
Табыныңда һәрвакытта
Бал да май, күмәч булсын.
Әй, ай батсын, ай батсын,
Кызарып таңнар атсын.
Тулган айдай киленне
Туганнарыгыз яратсын.

Өйгә алып кайтып җиткергәч, суны беренче булып кияүнең әти-әниләре, аннан кияү һәм калган кунаклар татып карый. Кайбер очракларда суны сатарга да мөмкин. Су эчкән кеше яшьләргә теләкләрен тели. Шул ук вакытта туй мәҗлесенә, килен төшерүгә багышланган йола җырлары да башкарыла. Килен төшүгә бәйләнешле әлеге йола, әлбәттә, яшьләрнең никахларын ныгыту, киләчәк тормышларын бәхетле итү, туй көнен онытылмаслык ясау өчен үткәрелә.

**Рәсемдә:**

**Арча районының Кушлавыч авылы егете Зөфәр Шәяхмәтов гаиләсендә дә борынгы йолаларга зур әһәмият бирелә, гореф-гадәтләр саклана. Шәяхмәтовлар гаиләсенә килен булып төшкән, Башкортстанның Әлмөхәммәт авылыннан башкорт кызы Зәлиягә дә су юлы күрсәттеләр. Әлеге йоланы күрсәтү күренеше барча кунакларны, Кушлавыч авылы халкын җәлеп итте, зур бер бәйрәмгә әйләнде. Бу йоланың яңартылуы өлкәннәрнең күңел хатирәләрен кузгалтты. Парлылар чишмә буена төшкәндә гармун, җыр-моң тавышыннан авыл гөр килеп торды.**

**Элек кызларны егетләр чишмә юлында күзләгән. Аларның булганлыгы, уңганлыгы да шунда сыналган: чиләгендәге мөлдерәмә суны чайпалдырып, түгеп алып кайтмыймы, янәсе... Яшь киленнең саф сулы чиләкләренә карап өлкәннәр теләк теләгән: «Бәхетләре шушы су сыман пакъ булсын!»**

**Яшь килен Зәлия чишмә суын, чиләкләрен тулы, мөлдерәмә итеп, түкмичә, үзләренә тигез, матур тормыш тели-тели алып кайтты.**

Рамил Мөхетдинов фоторәсемнәре

# «БӘЛЕШ УРЛАУ» *йоласы*

*Рәзинә СӘЙФЕТДИНОВА,*
*Питрәч районы*

**Татар халкы борынгыдан аш-суга оста булган. Бавырсак, бармак, бөккән, бүдәнә, вак бәлеш, горабия, гөбәдия, дучмак кебек тәмле ашлар пешергән. Милли ашларның үзенчәлеге халыкның тормыш рәвешенә бәйле булган.**

Бәлеш – татар халкының иң кадерле кунакларга, бәйрәм табынына гына пешерелә торган затлы ризыгы. Хәер, уңган хуҗабикәләр хәзер аны гадәти көннәрдә дә пешереп, гаиләсен сыйлый. Бәлешне дөге, карабодай белән җимештән дә, ит белән бәрәңгедән дә, кабактан, борайдан да пешерәләр.

Бәлешкә атап язылган бик күп табышмаклар, мәкальләр бар. Ә менә «Бәлеш урлау» йоласын күпләр белмидер әле. Аның нидән гыйбарәт булуын Питрәч районы Кибәк Иле авылыннан Фәүзия Шәяхмәтова сөйли.

– Безнең якларда әлегәчә «Бәлеш урлау» йоласы сакланып килә. Төннәр озайгач, кызлар, яшь киленнәр бер-берсенә кич утырырга йөрешәләр. Үзләре белән кул эшләре – бәйләргә, чигәргә, эрләргә алып киләләр һәм күңелле итеп, кызыклы хәлләр, мәзәкләр сөйләшеп кич утыралар. Аннары эшләгән эшләрен чагыштырып карыйлар, бер-берсен мактыйлар. Шактый эшләгәч, киленнәр, олырак яшьтәге апалар табын әзерли башлый. Бәлеш чыгарырга вакыт җитә. Тәрәзә төбенә шыпырт кына егетләр җыела. Әмма ничек кенә шыпырт йөрмәсеннәр, эчтәге кызлар аларны бик тиз сизеп ала. Менә бер егет тәрәзә капкачын сызып кына ачып, өй эчендәгеләрне күзәтә. Аны танып алган кыз тәрәзә аша егеткә күзгә күрсәтә. Бу – «синең өчен якты йөзем» диюне аңлата. Таныш булмаганнарга, яисә җан тартмаганнарга күзге

күрсәтмиләр. Көзге кулдан-кулга йөри. Тәрәзә аша төрле такмаклар әйтешеп җырлашалар. Бу вакытта өйгә ике егет кереп, бәлешне урлап кача. Кызлар моны сизмиләр. Уен-көлке тәмамлангач, егетләрне чакырып, өйгә кертәләр… Ә бәлеш юк… Кызларга җәза бирәләр һәм алар аны үтәгәч, бәлешне кире кертәләр, һәм бергәләп, күңелле итеп, табын артына утырып ашыйлар.

Автор фоторәсемнәре





# *Иманлы Апас ягының догалы бер бәйрәме*

2022 ел Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен рәсми рәвештә кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп үтү белән истә калды. Әлеге тарихи вакыйга уңаеннан районыбызда төрле дини чаралар узды. Шуларның берсе – быелның 25 гыйнвар көнне Апас районы мәдәният йортында булган «Халкыбызның чал тарихын, гореф-гадәтләрен саклау – безнең бурыч» дип аталган зур бәйрәм чарасын сезгә дә тасвирлап үтәсем килә.

Бәйрәм «Кояшкай» балалар бакчасына йөрүче нәниләрнең жырлы сәламе белән башланып китте. Балалар бакчасы хезмәткәрләре кечкенә генә этнографик музей – татар йорты да оештырган иде. Шул йортта татар әбисе үзенең оныклары белән театраль күренеш күрсәтте. Онықларның берсе, хаждан кайткан киемнәрен киеп, азан яңгыратса, икенчесе матур итеп дога кылды.

Фойеның һәр почмагында күңел жылысын кушып эшләнгән күргәзмәләр урын алган. Апас урта мәктәбе һәм «Салават күпере» балалар бакчасы хезмәткәрләре кунакларны балалар иҗат иткән кул эшләре белән таныштырды. Халыклар дуслыгы йортында һәм «Сәләт» балалар иҗат үзәгендә эшләүче кызлар калфак чигү һәм матур итеп яулык бәйләү буенча мастер-класслар оештырды. Ислам дине таләпләренә туры килгән күлмәкләр кигән хатын-кызларыбыз бәйрәм бизәге булды. «Апас таңнары» ресторaны әзерләгән хәләл ризыклар да, районның үзәк китапханәсендә сакланган дини китаплар да, мәдәният хезмәткәрләре авыл халкыннан берәмтекләп җыйган төрле чор тәсбихләре, шамаилләр дә күргәзмә яме иде. Апас туган якны өйрәнү музее хезмәткәрләре күргәзмәгә изге китабыбыз Коръәннең ниндиен генә әзерләмәгәннәр! Кунаклар балаларның Аллаһы исемнәрен гарәп телендә язып күрсәтүенә сокланып туя алмады. Әлеге күргәзмәдә, шулай ук, Сара Садыйкова исемендәге Апас балалар сәнгать мәктәбе укытучысы, рәссам Илсөяр Вәлиеваның, шулай ук җирле рәссам Илгиз Маликовның һәм мәчеткә йөрүче балалар белән эшләүче укытучы-логопед Фирүзә Сәлимуллинаның дин





өлкәсенә кагылышлы иҗат эшләре урын алды.

Бәйрәм чарасын сәхнәдә Апас районы башлыгы Айрат Габделхак улы Җиһаншин ачып җибәрде. «Апас районында барлыгы 58 мәчет эшләп килә. Мәчетләребездә 55 имам, 3 мөәзин дини таләпләргә туры китереп хезмәт итә: көндәлек, җомга, гает намазлары укыла, Ураза, Корбан, Мәүлид бәйрәмнәре үткәрелә. Даими рәвештә азан әйтелә. Коръән укучылар бәйгеләре булып тора», – диде ул. Чыгышы ахырында дин әһелләренә: «Мобилизациягә эләккән егетләребезне дә догадан калдырмагыз. Хәзерге көндә алар безне, илебезне саклый. Аларга рәхмәт әйтеп, изге догада торыйк, исән-имин әйләнеп кайтсыннар!» – дип тә мөрәҗәгать итте. Әлеге кичәдә Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте башлыгы урынбасары, «Кол Шәриф» мәчете имам-хатыйбы Илфар хәзрәт Хәсәнов, шулай ук Татарстан Республикасының баш казые, Балтач районы мөхтәсибе Җәлил хәзрәт Фазлыев, «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Казан «Апанай» мәчете имам-хатыйбы, тарих фәннәре кандидаты Нияз хәзрәт Сабиров, Апас районы мөхтәсибе Мирхәт хәзрәт Җамалиев катнашты.

Сәхнәдә «Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам кабул ителү» дип аталган театральләштерелгән күренеш күрсәтелде. Үзәк китапханә хезмәткәре Гөлинә Муллаәхмәтова мөнәҗәт башкарды, районыбызның талантлы җырчы егете Айрат Айтуганов «Дога кылыйк әти-әниләргә» дип аталган мәгънәле җырын бүләк итте. Апасның туган якны өйрәнү музее җитәкчесе, районыбызның «аяклы энциклопедиясе» Рәмис абый Ногманов үзенең чыгышында тарих төпкелләренә үтеп керде.

Тумышы белән Апас районы Морзалар авылы кешесе, XIX-XX гасырлар чигендә яшәгән һәм Буа шәһәрендә имам булып эшләгән татар дин белгече Нургали Хәсәновның биографиясенә нигезләнеп, маҗаралы тарихны чагылдырган, Буа дәүләт театры тарафыннан куелган «Дәрвиш» моноспектакле күрсәтелде. Спектакльдә бердәнбер рольне Татарстанның халык артисты, Буа дәүләт театры җитәкчесе Раил Садриев башкарды.

Өч сәгатькә сузылган әлеге матур чара бер сулыштай үтеп тә китте. Һәркем, мондый тәрбияви чаралар ешрак булсын иде дигән теләктә калды.

**Земфира МӨХӘММӘТШИНА,**
**Апас халык театры режиссеры**

Автор фоторәсемнәре

# *Мөнәҗәтләр – җан авазы*

*Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,*
*язучы, филология фәннәре докторы, Татарстанның, Россиянең атказанган фән эшлеклесе*

Татар халык иҗаты – тормыш-яшәешнең төрле кыйтгаларын сүз-сурәт белән тасвирлаган кыйммәтле рухи мирасыбыз. Маҗаралы вә тормышчан әкиятләр, мәгърур дастаннар, фаҗигале бәетләр, тапкыр мәкаль-әйтемнәр, кешенең сөенечле дә, сагышлы да хисләрен чагылдырган лирик, тарихи йола җырлары янәшәсендә, бары тик ислам динен тотучыларга гына хас, халык сүз сәнгате белән язма шигърият бердәмлеге җимеше – илаһи жанр – мөнәҗәтнең «йөрәге тибүе» дә мәгълүм. Шактый күп санлы һәм төрле лөгатьле мәмләкәтләр даирәсендә киң таралган һәм халыкның «җан авазы» буларак кабул ителгән мөнәҗәтләр бер дә юктан гына барлыкка килеп, фольклорның түр башына «менеп» утырмадылар. Мөнәҗәт – халык күңеленә, рухына ислам диненең кануннарын мәңге онытмаслык итеп сеңдерү көченә ия лирик жанр. Мәгълүм булганча, гарәпләрнең Мәккә, Мәдинә шәһәрләрендә кабул ителгән дин үзенең самими, савыктыргыч илаһи нурлы көче белән сибелеп, таркалып, әлегәчә потларга таянып яшәгән кабиләләрнең күңеленә хуш килә. Ислам тиз арада Гыйрак, Иран, Күвәйт, Төркия, Мавр Испаниясе, өлешчә Кытай, Һиндстан илләренә үтеп керә. Азак (Азов) диңгезе, Идел-Чулман елгалары тирәләрендә гомер иткән, иген иккән, балалар үстергән болгар бабаларыбыз әле Мөхәммәд пәйгамбәр исән-имин чакта ук исламга тартылалар. Дәүләти, хәрби, игътисадый, мәдәни яктан алдынгы империяләрнең берсе дәрәҗәсенә күтәрелгән Хәлифәт үз йогынтысын җиһанның төньягында озак яшәгән халыкларга иңдерү турында кайгыртып, 922 елда Әхмәд ибн Фадлан җитәкчелегендәге илчелеген Урта Идел буена юнәлтә. Үзләре дә җылы якта яшәгән мәмләкәтләр, дәүләтләр белән аралашу юлларын эзләгән бабаларыбыз шул арадашчылар йогынтысында һәм күңелләре тартуы нәтиҗәсендә мәҗүси Тәңречелектән китеп, ике дини тәгълимат арасында эчке рухи якынлык күреп, ирекле рәвештә, ислам динен кабул итәләр. Кануннары ышандырырлык уйланылган яңа галәмгә (идеологиягә) табынуның күп сәбәпләреннән берсе – күпчелек инсанны куркытып торган үлемнән соң, диннең катгый таләпләр үтәгәннәрне мәңгелек җәннәтнең барлыгына ышандыру көченә ия булуы иде. Мөэмин-мөселманнар өчен Алла иң югары рухи таяныч һәм гадел хөкемдар буларак күзаллана. Авырлык килгәндә Аллаһы Тәгаләгә сыену, өлкәннәргә шәфкать, ата-ананы олылау, намуслы хезмәт, гарип-горабаларга, ярлыларга ярдәм итү кебек кануннарның инсафлы күңелләргә хуш килүе бәхәс тудырмый. Ике халәтне, ягъни үлем белән яшәүне капма-каршы куя алымы белән оҗмахның асыл яклары, нигъмәтләре белән ымсындыруы кешеләрдә матур киләчәккә («теге дөньяда» булса да) өмет чаткылары уята. Җәннәтнең тарту көчләрен сурәтләүдә мөнәҗәтчеләр хыялларына тулы ирек бирәләр.

*Дөнья йорты фанидыр,*
*фанидыр нигъмәтләре,*
*Бакый итеп безгә Аллаһ кыйлгандыр*
*җәннәтләрне.*
*Җәннәт эчрә мөэмин колың,*
*хөллә булыр туннары,*
*Ни теләсәң, шуңа әзер торыр хурлары.*
***(«Җәннәт эче – хозур бакча»).***

Ислам кануннарын халык күңеленә ирештерүдә беренче үрнәкләр хәзер Сүрия урнашкан җирлекләрдә туган көйле, моңлы мөнәҗәтләр һәм аларга якын өслүбтә иҗат ителгән шәрыкъ, бигрәк тә суфичыл мистик шигърият ярдәмгә килә. Үзәктә шул ук «ике дөньяны» янәшә кую галәме (идеологиясе) алга чыга.

*Игелек кыл!*
*Иң нык күпер шул булыр ул!*
*Җәннәтеңә иткән тугры юл булыр ул!*
***(Юныс Әмрә).***

Ислам тәгълиматын кабул итү халкыбызның киләчәге өчен бәяләп бетергесез олы вакыйга була. Күренекле тарихчы Р. Әмирханов язганча: «...Ислам әхлагыбыз сагында гына түгел, милләтнең этник сафлыгы сагында да торды... Ислам, шәригать ата-бабаларыбызның гасырлар дәвамында яшәү рәвеше, Иманы булган»[1]. Ислам дине белән берүк вакытта диярлек таралган мөнәҗәт – дин белән Адәм балалары арасында арадашчы һәм элемтәче вазифаларын үти. Аллаһның кодрәтенә, бөеклегенә, бердәнберлегенә инангач, дини кешеләрнең күңел серләре шигъри юлларга саркый башлый. Татар мохитендә дә мөнәҗәтләр Аллаһка табынган эчтәлекләре, көйле, моңлы сурәтлелек чаралары белән теләктәшлек табалар һәм яшәешебезнең төрле чорларында аның юанычы, рухи таянычы дәрәҗәсенә күтәреләләр. Казан ханлыгы буйсындырылгач, исламнан биздереп, көчләп чукындырулар чорында, 1917 елгы инкыйлабтан соң, аларда ислам дине белән бәйле хис алга сөрелә дип, мөнәҗәтләр мәгариф, фән игътибарыннан читкә тибәрелделәр. Халык нинди авыр, дәһшәтле




**Россиядә Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан нәшер ителгән җыентыкта төрле жанрдагы, шул исәптән дини һәм фәлсәфи, яшәү һәм үлем, сабырлык, ана һәм бала турында мөнәҗәтләр тупланды.**

**Мөнәҗәтләр 2022 елда Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге хезмәткәрләре тарафыннан Әтнә, Буа, Казан, Аксубай, Саба муниципаль районнарына оештырылган фәнниэтнографик экспедицияләр вакытында язып алынды.**

Җыентык белән кюар-код аша кереп танышырга мөмкин.

[1] Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1997. – Б. 138.

изүләр заманында да үзенең рухи таянычыннан, сәнгати байлыгыннан баш тартмый, мөнәҗәтләр халык күңелендә һәм һәр төрле язма чыганакларда сакланып, иҗат ителә, тарала торалар. Төп үзенчәлеге Аллага табыну, ярлыкау, киләчәген аңа тапшыру булган мөнәҗәтләрнең саклануына үз өлешләрен башкаручылар, мөнәҗәт әйтүчеләр дә кертәләр. Дини бәйрәм көннәрендә Миңгол Галиев, Җәмил Зәйнуллин, Зөһрә Сәхәбиева һәм башкалар башкаруында мөнәҗәтләрне ишетмәгән, илһамланып сокланмаган татар телле кеше юктыр. Мөнәҗәтләрнең күбесен шагыйрьләр, шәкертләр, дин әһелләре иҗат итсә дә, еш кына үз исемнәрен куймаганнар, шуңа күрә алар халык теленә кереп, рухи мирасыбыз булып киткәннәр. Мөнәҗәт – фани дөнья белән «теге» дөньяны тоташтыручы космик жанр. Аның төп максаты – җирдәге тормышның, ыгы-зыгының, байлык, мал артыннан кууның вакытлы булуын, ахыр чиктә барчабызның да Аллаһ хозурында икәнлегебезне күңелгә сеңдерү. Кем булсаң да, нинди генә «югары кәнәфиләр биләсәң» дә, адәм баласы тормышының кыска булуын, мәңгелек турында вакытында уйлауның зарурлыгын, Алла кулында икәнлегебезне бер мизгелгә дә онытмаска чакыруы, искә төшереп торуы белән үзенчәлекле. Мөнәҗәтләр тарихы белән кызыксыну шуны күрсәтә, бу борынгы жанр «бабайлар» истәлеге дип уйлаучылар бик нык ялгышалар икән. Шагыйрә Флера Тарханова бакыйлыкка күчүе алдыннан «Рамазан» мөнәҗәтен язып чыкса, 2016 елның июнь аенда кулыма «Ата күңеле балада...» дигән мөнәҗәт килеп керде, аңа композитор Әнвәр Шәрәфиев көй дә язды. Аның авторы язучы профессор Фарсель Зыятдинов. Әүвәл ул шулай ук шагыйрә, җырлар авторы Фираясын югалта, бераздан улы Айваз да аны ташлап мәңгелеккә күчә. Йөрәге сыкрануын, әрнүен, сызлануын, югалтуның кайтарып булмаслыгын аңлау үзеннән-үзе шигъри юлларга иңә. Шәхси кичерешне ачуның иң кулае мөнәҗәт дип табыла. Тора-бара әсәрнең исеме дә үзгәрә. Беренче нөсхәдә «Ата күңеле балада...»ны «Кайтып керерсең күк тоела» исеме алыштыра. Үзгәртү шәкли алым гына булмыйча, Алладан, Раббыбыздан мәрхәмәтлек сорау, ярдәм, өмет итү мотивлары килеп керә.

*Тәңребездән рәхимлек сорап,*
*Хәсрәтемне елап юамын.*
*Раббем кушып бер иртәдә*
*Кайтып керерсең күк тоямын.*

Татар сүз сәнгате Кол Шәриф, Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакыргани, Һ. Сали кебек шагыйрьләр сызган юлга тугрылыклы калып, мөнәҗәтнең офыкларын киңәйтүне дәвам иттерә. Казан ханлыгы чорының бөекләре турында «Сөембикә» (1987), «Колшәриф» (1990), «Мөхәммәдьяр» (1996) кебек мифопоэтик поэмалар авторы Ә. Рәшитнең Мөхәммәд пәйгамбәр образын тудыруга алынуы табигый иде. Шагыйрь ислам динен тотучылар өчен изге затның шигъри сынын тудырганда, тарихи, әдәби чыганакларга таянып иҗат итүе, Мөхәммәдне идеаллаштырып сурәтләвеннән сизелеп тора.

*Кинәт кенә әллә нәрсә булды,*
*Ишек алды якты нурлар белән тулды.*
***(Ә. Рәшит. «Мөхәммәд»).***

«Пәйгамбәрләр турында кыйсса» шигырендә Н. Әхмәдиев мөнәҗәтләрдә сибелгән фикерләргә таянып, пәйгамбәрләрнең дә адәм балалары булуларына басым ясап, «Аларга да ташлар аткannар, хак илчесе дип тормаганнар», «Пәйгамбәр дә судан яралмаган, кендекләре җиргә береккән», дигән җисми күзәтүләре белән уртаклаша. Г. Сәгыйров «Нух көймәсе» шигырендә халык, милләт язмышын иҗтимагый-фәлсәфи биеклеккә күтәреп сурәтли. Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге хезмәткәрләре 2022 елда Саба, Әтнә, Арча, Аксубай, Буа районнарында, Казан шәһәрендә оештырылган экспедицияләр вакытында дистәләгән мөнәҗәтләр (яңараклары һәм төрле вариантлары) язып алганнар. Башкаручыларның күбесе мәдрәсәләрдә укыган яисә үзлегеннән дини белем алган, нигездә үткән гасырның 1960-1970 елларында туган ханымнар. Ир-ат затыннан бер Ситтигуллин Рафыйл (1962 елгы) гына «Укы Коръән илә намаз» мөнәҗәтен көйләп әйтеп биргән. Яңа язып алынган мөнәҗәтләрнең күбесе җыентыкларга кертелгән булсалар

да, үзләренә күпмедер күләмдә замана рухын сыйдырганнары да бар. «Картаябыз димик әле, мөнәҗәтләр көйлик әле», «Буш үткәрмә вакытыңны», «Сабыр итик» һәм башка мөнәҗәтләрне көйләп биргәннәр. Китерелгән мисаллардан гына да үзеннән-үзе шундый нәтиҗә соралып тора: бәетләр шикелле үк, мөнәҗәтләрнең һаман да язылып торуы, аларның тормышчан нигезле булуы һәм кешенең иң авыр мизгелләрдә кулына каләм тоттырган кайгы-хәсрәте белән уртаклашкан әдәби төр дәрәҗәсенә күтәрә, халык, туган телебез исән булганда, аның яшәячәгенә инандыра. Мөнәҗәтләрне фәнни өйрәнү, кабатланмас үзенчәлекләрен тикшерү юнәлешендә дә эзләнүләр тукталып тормый. Халык иҗаты белән язма поэзия бердәмлегендә туган, жанрлык хасиятләре, шигырь төзелеше җәһәтеннән төрле, гаруз системасы янында силлабикага корылган мөнәҗәтләрне төркемнәргә бүлүдә барча галимнәрне, җәмәгатьчелекне канәгатьләндерелек классификацияне эзләү әлегәчә дәвам итә. Мөнәҗәтләрне фәнни-гамәли өйрәнүгә К. Хәснуллин, М. Бакиров, Ф. Урманче, К. Миңнуллин, Ф. Йосыпов, Җ. Зәйнуллин һәм башка галимнәр, һәвәскәрләр житди өлеш керттеләр. Мөнәҗәтләрне төркемнәргә бүлүдә фикер төрлелеге яшәсә дә, нигездә мәгънәви эчтәлекләре буенча бер-берсен кабатламаган өч олы төркемгә «җан авазларыбыз» сыешып бетәләр кебек. Менә алар:

1. Дини мөнәҗәтләр.
2. Фәлсәфи-әхлакый эчтәлекле мөнәҗәтләр.
3. Тормыш-көнкүреш, яшәеш мөнәҗәтләре.

(Мәкаләнең дәвамы киләсе санда).

**Кулланылган әдәбият**

Бакиров М. Х. Татар фольклоры. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 299-348. Хан кызы / Төз. Җ. Зәйнуллин. – Казан: Мәгариф, 1994. – 95 б.
Садыкова А. Х. Татарские мунажаты в типологическом освещении. – Казань, Тат. кн. издат., 1999. Нигъмәтҗанов М. Татар халык җырлары. – Казан, 1976. – Б. 25.
Сибгатуллина Ә. Татар әдәбиятында суфыйчылык. – Казан, 2000. – Б. 334.
Хәснуллин К. М. Мөнәҗәтләр һәм бәетләр. – Казан: Раннур. – 724 б.

## ИНАНДЫМ БЕР АЛЛАГА

*Инандым бер Аллаһка*
*Аллаһның барлыгына*
*Аллаһның берлегенә,*
*Бердер Иляһем бәнем*
*Аллаһның берлегенә.*
*Бердер Иляһем бәнем.*

*Бер Аллаһым үзеннән*
*Һәр нәрсәне бар иткән*
*Һәркемгә ризык биргән.*
*Бердер Иляһем бәнем*
*Һәркемгә ризык биргән*
*Бердер Иляһем бәнем.*

*Аллаһым сүзе – Корьән*
*Пәйгамбәрләрдән килгән*
*Безгә ул китап булган.*
*Бердер Иляһем бәнем*
*Безгә ул китап булган*
*Бердер Иляһем бәнем.*

*Ул Мөхәммәд Мостафа*
*Пәйгамбәремдер бәнем*
*Шәфәгатьчемдер бәнем.*
*Бердер Иляһем бәнем*
*Шәфәгатьчемдер бәнем*
*Бердер Иляһем бәнем.*

*Адәмдер бәнем атам,*
*Хавадыр бәнем анам*
*Милләтемдер Ибраһим.*
*Бердер Иляһем бәнем*
*Милләтемдер Ибраһим*
*Бердер Иляһем бәнем.*

**Башкара: Җиһаншина Хөрия Сәфәргали кызы (1965 елда туган )**
**Язып алынды: Буа районы, Яңа Чәчкап авылы.**
**Язып алу вакыты: декабрь, 2022 ел.**

# «СӘЙЛӘН» кешеләргә шатлык бүләк итә

**«Сәйлән» бию ансамбленең оешуына 30 ел булып килә – коллектив үзенең алыштыргысыз сәнгать җитәкчесе Лилия Нурмөхәммәтова белән бергә 1994 елдан бирле эшли. Ул «Утренняя звезда», «До-ми-солька», «На балу у Золушки» кебек телетапшыруларда катнашканнан соң киң танылу алды.**





Ансамбль шәһәр һәм республика күләмендәге бәйрәм чараларының бер бизәгенә әверелде. Алар муниципаль, региональ, республика күләмендә, Россия күләмендә һәм халыкара фестивальләрдә, конкурсларда һәм смотрларда катнаша. Коллектив 2011 елдан бирле «Россия Федерациясе халык иҗатының атказанган коллективы» исемен йөртә. Хореография өлкәсендә халык традицияләрен саклаган һәм үстергән өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан «Халык коллективы» мактаулы исеме бирелде.






Хәзерге вакытта ансамбль репертуарында 200дән артык хореографик композиция бар.

Ансамбльнең иң актив кызлары-егетләре язмышларын хореография белән бәйләгән – Санкт-Петербург, Мәскәү, Казан һәм Чаллыда профессиональ коллективларда эшлиләр. И. Моисеев исемендәге халык биюләре ансамбле артисты Алсу Гайфуллина – ансамбльнең горурлыгы.

Хореографиягә мәхәббәт, кешеләргә шатлык бүләк итү – ансамбльнең иҗат максаты.




Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# ИСӘНМЕ, ЯЗ, КИЛДЕҢМЕ!

**(Яз белән диалог)**

Moderato

**Наилә Яхина сүзләре һәм көе**




*Балалар:*
Исәнме, яз, килдеңме!
Безне саг(ы)нып килдеңме?
Агачларга, куакларга
Яшел чуклар элдеңме?

*Яз:*
Саумы, нәни дусларым!
Нурлы минем чукларым.
Кояшлы көннәр китердем
Яңгырлар да коярмын.

*Балалар:*
Без йөрибез болында
Чәчәкләр бик күп монда
Чәчәкләрне өзәбез.
Тәкыяләр үрәбез.

*Яз:*
Саумы, нәни дусларым!
Нурлы минем чукларым.
Кояшлы көннәр китердем
Яңгырлар да коярмын.

*Балалар:*
Кошлар очып кайтканнар
Яз көнендә урманга.
Башка берни дә кирәкми
Матур көннәр булганда.

*Яз һәм балалар:*
Без уйныйбыз «түгәрәк»
Тотынышып, бергәләп.
Матур Яз да безнең белән
Жырлашабыз бергәләп.

«Татарханә» проектының «Татар табыны» рубрикасыннан. Рубриканы «Тәмле булсын» рестораннар челтәре җитәкчесе, Татар ашлары һәм мәдәнияте Халыкара ассоциациясе президенты, Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре, танылган аш-су остасы **Резидә Кыям кызы ХӨСӘЕНОВА** алып бара.

# ЗУР *бәлеш*

**Бәлеш – камыр эченә төрле эчлекләр салып мичтә пешерелгән кунак ашы. Татар халкында бәлешнең нинди генә төре юк: дөгеле бәлеш, борай бәлеше, ит бәлеше...**



Зур бәлеш гадәттә мөгезле эре терлек итеннән генә пешерелә. Халыкта бу бәлешне шулпалы ит бәлеше диләр. Әстерхан татарларында – «мәлеш», себер татарларында «пәлеш» вариантлары да күзәтелә.

Бәлешне табынга үз табасында чыгаралар. Аны кисү табын артындагы иң өлкән кешегә тапшырыла. Башта бөкесе ачыла, аннан матур итеп түгәрәкләп капкачы киселә. Бәлешне табында утырган һәркемнең тәлинкәсенә салып бирәләр. Бәлеш төбен – «кызлар теле» дип тә йөртәләр. Аны шулай ук табында утырган һәркемгә салып чыгалар.

Юрауларга килгәндә, бәлеш өстен каплаганда сөйләшергә ярамый диләр. Сөйләшсәң, бәлеш тишелә, имеш.

Бәлеш кем ягында пешерелүенә карап төрлечә атала. Мәсәлән, кияү бәлеше – кияүне сыйлау өчен пешерелә, (себер диалекты); кодагый бәлеше – туй вакытында кияүнең яки кызның эти-әниләре пешергән бәлеш; кыз бәлеше – килен төшкән-



дә, кияү өенә кыз ягыннан китерелгән бәлеш (Красноуфим, Әстерхан сөйләше). Кыз бәлешен өстәп салмыйлар, бары парлы итеп ике яки дүрт чынаяк чәй бирәләр.

Бәлеш чыгару (Пермь сөйләше) – туй бәлешен табынга чыгарып кунакларга кую.

«Итле, бәрәңгеле бәлеш өстәл саен чыгарыла. Элек пичтә пешерәдерийек, бәлеш пешерергә бик әйбәт ийе пичләр. Исе чыкса, морҗаны ачып куйадырыек».

«Бәлешнең өстен ачып чыгаралар. «Кем пешергән бу бәлешне, чыксыннар, күренсеннәр әле», – диләр. Хатыны «кот-котыйк» дип, ире «кикрикүк» дип килеп чыга. Аларның икесен дә урындыкка бастыралар да җырлаталар:

Кыр түренә бармагыз,
Кыр үрдәген атмагыз.
Бу бәлешне ашаганда
Телегезне йотмагыз».



## КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР

**Камыр өчен:**
600 грамм он,
1 данә йомырка,
ярты стаканнан күбрәк сөт,
150 грамм көнбагыш мае,
1 балкашыгы шикәр комы,
тәменчә тоз.

**Эчлек өчен:**
800 грамм сыер ите,
1,2 килограмм бәрәңге,
3 данә суган,
150 грамм атланмай,
тәменчә тоз, борыч,
150-200 грамм шулпа.



**1**

Савытка 150 грамм көнбагыш мае, 150 мл сөт, тоз салып, 1 йомырка сытып яхшылап болгатабыз. Аннары он өсти-өсти камыр басабыз. Камыр савыт кырыена ябышмаска тиеш. Әзер булган камырны куна тактасында төшереп, ял итәргә куябыз.







**2**

Камыр ял иткән арада эчлек әзерлибез. Бәрәңгене түгәрәкләп, ит белән суганны шакмаклап турыйбыз. Тәменчә тоз, борыч сибеп, эчлекне болгатабыз.





**3**

Камырның дүрттән бер өлешен алып куеп, калган зуррак өлешен 4-5 миллиметр калынлыкта таба кырыеннан бераз чыгып торырлык итеп җәябез. Табаны камыр өстенә куеп үлчәп карарга мөмкин. Камыр ертылмасын өчен таба кырыен түгәрәкләп сөлге белән әйләндереп алабыз. Килеп чыккан җәймәне табага җәябез.





**4** Әзер әчлекне табадагы җәймәгә өеп салабыз һәм камырның кырыйларын күтәртеп бөгәбез. Уртасына атланмай ваклыйбыз. Аннары камырның калган өлешен җәеп, бәлешнең өстенә ябабыз, читләрен чеметеп, бөреп чыгабыз. Капкачны уртадан тишеп, камырдан бөке ясап, бәлешне каплап куябыз. Калган камырдан махсус фигуралар белән төрле бизәкләр кисеп, бәлешне бизибез.



**5**

Бизәп бетергәч, бәлешне 180 С кадәр җылытылган духовкага тыгабыз. Өсте кызарып киткәннән соң, духовканың җылылыгын (160° С) киметәбез. Бәлешне 1-1,5 сәгать тотканнан соң, духовкадан алып, бөкесен ачабыз һәм алдан әзерләп куйган шулпаны салабыз да, бөкесен ябып, пешеп чыкканчы тотабыз.



**6**


Бәлеш пешеп чыккач, духовкадан алып, йомшарсын өчен өстен бераз каплап торабыз. Өстәлгә чыгаргач, капкачын ачып, кискәләп, әчлеге белән бергә таратабыз.

**Ашларыгыз тәмле булсын!**


Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# Шахворд

Хөрмәтле укучылар! Таблицадагы хәрефләр тезмәсеннән шахмат фигурасы атның дөрес йөреш тәртибен кулланып, шагыйрь Галимҗан Латыйпның «Кошлар кайткач» шигыренең бер куплетын укыгыз.

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | а | у | ш. | л | д | а | р |
| з | я | Е | л | л | У | г | ы... |
| к | к | г | а | | ң | а | д |
| а | м | о | ү | е | т | Е | а |
| р | ә | п | | е | | ы | м |
| ә | л | к | л | | я | д | л |
| л | а |  | | | л | н | Я |
| й | һ | | | з | | м | а |
| л | ө | л | б | о | я, | м | а |
| е | у | з | к | ь | р | б | а |

**Шахворд җавабы – саннарда**
Бер сан бер хәрефкә туры килә.
Шигырь 69 хәрефтән тора.

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 17 | 14 | 33 | 2 | 19 | 50 | 35 |
| 15 | 32 | 1 | 18 | 49 | 34 | 3 | 20 |
| 30 | 13 | 16 | 47 | | 63 | 36 | 51 |
| 45 | 60 | 31 | 62 | 67 | 48 | 21 | 4 |
| 12 | 29 | 46 | | 64 | | 52 | 37 |
| 59 | 44 | 61 | 66 | | 68 | 5 | 22 |
| 28 | 11 |  | | | 65 | 38 | 53 |
| 43 | 58 | | | 69 | | 23 | 6 |
| 10 | 27 | 56 | 41 | 8 | 25 | 54 | 39 |
| 57 | 42 | 9 | 26 | 55 | 40 | 7 | 24 |

**Шахвордның җавабы:**

Кошлар кайткач
Елгада бозлар кузгалды...
Елмая, көлә кояш.
Урамнар буйлап агылды
Ямьле һәм күңелле яз.
(Галимҗан Латыйп)

**Педагогия фәннәре кандидаты, Халыкара педагогик белем фәннәре академиясе академигы Нәҗип ШАКИРҖАНОВ төзеде.**

# Истәлекле даталар
2023

## АПРЕЛЬ

**2 апрель**

Актёр, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты Евгений Андриянович Кузинның тууына 90 ел (1933-2004)

**2 апрель**

75 ел элек «Алтынчәч» операсы өчен (Муса Җәлил либреттосы) композитор Нәҗип Җиһановка СССРның Дәүләт премиясе бирелә (1948)

**5 апрель**

Рәссам-проектлаучы Рәшит Лотфулла улы Фәттаховка 70 яшь (1953)

**10 апрель**

140 ел элек Бакчасарай шәһәрендә төрки-татар телендә «Тәрҗеман» газетасы нәшер ителә башлый (1883-1918)

**11 апрель**

Гамәли бизәлеш рәссамы Александр Сергеевич Маяковка 75 яшь (1948)

**14 апрель**

Рәссам, педагог Мария Михайловна Васильеваның тууына 120 ел (1903- 1964)

**15 апрель**

Театр белгече, библиограф Һәнүз Котдус улы Мәхмүтовның тууына 90 ел (1933-1996)

**19 апрель**

Гамәли бизәлеш рәссамы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б. Урманче исемендәге премиясе лауреаты Анатолий Николаевич Егоровка 75 яшь (1948)

**21 апрель**

Режиссёр, педагог, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Равил Рәхим улы Тумашевның тууына 100 ел (1923-2016)

## МАЙ

**1 май**

Гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы Дамир Әхмәт улы Илдаровка 75 яшь (1948)

**5 май**

Рәссам, график Флүс Нурулла улы Төхбәтуллинга 75 яшь (1948)

**11 май**

Монументаль бизәлеш сәнгате рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б. Урманче исемендәге премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының халык рәссамы Игорь Николаевич Башмаковның тууына 80 ел (1943-2012)

**16 май**

Татарстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Дамирә Нәҗмиҗан кызы Кузаеваның тууына 75 ел (1948-1993)

**20 май**

Актёр, режиссёр, Татарстан Республикасының халык артисты Айдар Садри улы Хафизовның тууына 80 ел (1943-2020)

**30 май**

Әдәбият тәнкыйтьчесе, шагыйрь, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Мөдәррис Харис улы Вәлиевнең (Салих Маннапов) тууына 70 ел (1953-2020)

## ИЮНЬ

**13 июнь**

Рәссам Радик Вакыйф улы Минһаҗевка 60 яшь (1963)

**15 июнь**

Актриса, Татарстанның халык артисты, Республиканың М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Зөлфирә Сафи кызы Зариповага 70 яшь (1953)

**15 июнь**

Рәссам Әнвәр Камил улы Сәйфетдиновка 60 яшь (1963)

**15 июнь**

Гамәли бизәлеш рәссамы Фәридә Мирзанур кызы Сәхабетдиновага 60 яшь (1963)

**20 июнь**

Рәссам Илдус Миңнулла улы Насретдиновка 90 яшь (1933)

**25 июнь**

Хормейстер, педагог, Татарстанның халык артисты Венера Хәсән кызы Гәрәеваның тууына 80 ел (1943-2020)

**27 июнь**

Шагыйрь Фәннур Шәйхенур улы Сафинның тууына 75 ел (1948-1992)

**30 июнь**

Язучы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, М. Горький исемендәге әдәби премия, Г.Р. Державин исемендәге Республика премиясе лауреаты Нонна Николаевна Орешинаның тууына 90 ел (1933-2015)

**https://kitaphane.tatarstan.ru сайтыннан алынды**

**Кадерле укучыларыбыз!**
2023 елның беренче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

**Индексыбыз – ПА 183**
**Өч айга язылу бәясе – 283 сум 39 тиен**
**Ярты елга язылу бәясе – 566 сум 78 тиен**

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!